РЕНАТ ХАРИС

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ

Избранные произведения
В семи томах

**Том 6**

*Произведения для детей*
*Переводы, песни, рисунки*

# РЕНАТ ХАРИС

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
2006

Сайланма әсәрләр
Җиде томда
**6 том**
*Балалар өчен әсәрләр*
*Тәрҗемәләр, җырлар, рәсемнәр*

# РЕНАТ ХАРИС

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2006

УДК 821.512.145-1
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Х33

Җыентыкны төзүче, текстларны хәзерләүче, кереш сүз авторы — филология фәннәре кандидаты, ТДГПУ доценты
*Фәридә Хәсәнова*

**Редколлегия:**

*З.Р.Вәлиева, Р.И.Вәлиев, Т.А.Миңнуллин, И.М.Ибраһимов, Д.С.Шакиров, Х.Г.Әюпов, Р.Х.Корбанов*

**Харисов Р.М.**

Х33 Сайланма әсәрләр: 7 томда / РенатХарис;Төз. һәм кереш сүз авт. Ф.Хәсәнова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2006.

ISBN 5-298-03912-X

6 т.: Р.Харис иҗатында музыка һәм рәсем сәнгате. — 2006. — 351 б.

ISBN 5-298-03918-9

Ренат Харисның бу томына мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен шигырьләр һәм җырлар, урта яшьтәге мәктәп балалары өчен пьеса, оратория өчен либреттолар, кантата, ода, җыр һәм романслар, тәрҗемәләр, шагыйрьнең рәсемнәре, һәм татар, рус, инглиз телләрендә шул рәсемнәргә карата язылган шигырьләре урнаштырылды.

ISBN 5-298-03918-9 (6 т.)
ISBN 5-298-03912-X

© Татарстан китап нәшрияты, 2006
© Харисов Р.М., 2006



# Төзүчедән*

Җыр — поэзиянең халык күңеленә иң якын торган жанрларыннан берсе. Шигырь яратучылардан җыр сөючеләрнең күбрәк булуы да шуны күрсәтә. Хәзер бездә җыр иҗат итүчеләргә кытлык сизелми кебек. Бу эшкә профессионаллар да, үзешчәннәр дә күпләп тартыла. Сыйфат мәсьәләсе аксап барса да, сан ягыннан борчылырга урын юк сыман.

Уңышлы җыр иҗат итү өчен җыр текстының яхшы булуы гына җитми. Җырда, шагыйрь фикере белән композитор тойгысы бергә кушылып, тәңгәл килгән шигъри сурәт белән музыкаль образ булырга тиеш.

Ә Ренат Хариска килгәндә, ул җыр текстларына бик таләпчән карый. Бары тик музыкаль эффектка гына корылган, мәгънә ягы сай булган текстларны ул кабул итә алмый. Шуңа да үзенең шигырьләрендә үк бу турыда әйтеп бирә:

Бәхетлерәк була алмас идем,
минем җырым, ахры, тумыштан,
бармак күрсәткәч тә ихахайлап
көлгән такмак белән сугышкан.

Чынлап та, җырга тирән лиризм, җылылык, кешелеклелек хас булырга тиеш. Шул ук вакытта җырда иҗатчының тормышка, үзе тасвирлаган чынбарлыкка мөнәсәбәте дә чагыла. Дөрес, Р.Харис җыр текстларында, халык җырларындагы кебек, «бөрлегәннән кызыл йөзләрең», «карлыганнан кара, ай, кашларың» кебек чагыштырулар очрамый. Р.Харисның җыр текстлары романс характерында булулары белән аерылып тора, ягъни классик таләпләрдән чыгып караганда, көйләү характерындагы, күбесенчә мәхәббәт темасы өстенлек иткән зур булмаган лирик шигырьләр. Романслар язу татарда Ә.Ерикәй, С.Хәким һ.б. исемнәр белән дә бәйләп карала. Ә менә русларда А.Пушкин, М.Лермонтов, Н.Некрасов, А.Фет, Ф.Тютчев, А.Блок, С.Есенин әсәрләренә романслар күпләп иҗат ителгән.

Р.Харисның шактый шигырьләре музыкаль әсәрләр булып киткән, дигән идек инде. Бүгенге көндә аның шигырь текстларына 130дан артык җыр һәм романс, 3 камера-вокал хор циклы, 5 кантата, 4 оратория иҗат ителгән. Ул шулай ук 2 опера либреттосы, балет либреттолары авторы да. Ә шагыйрьнең иҗатына мөрәҗәгать итүче татар классик композиторларыннан Н.Җиһанов, Р.Яхин, А.Вәлиуллин, Б.Мулюков, Ф.Әхмәтов, И.Шәмсетдинов, С.Садыйковаларның исемнәрен атап үтү кулай булыр. Хәзерге буын композиторларыннан М.Яруллин, Р.Еникеев, Р.Гобәйдуллин, И.Якупов, Л.Любовский, Р.Ахиярова, Ш.Тимербулатов, Р.Абдуллин, Р.Абязов, И.Мәҗитов шагыйрьнең шигырьләрен җыр, романсларга әверелдергәннәр. Яшьләр дә әлеге иҗатка битараф түгел. Алар арасыннан И.Байтирәк, С.Вәлиди, Ф.Фәизова, А.Софийскаялар аерылып тора.

---

* Автор музыка өлкәсендәге кайбер мәгълүматларны Г.Н.Мөхәммәтҗанованың фәнни эшеннән алуын белдерә.

Музыка жанрына Р.Харис иҗатының башлангыч чорында ук мөрәҗәгать итә. Ул үзе үк бер шигырь җыентыгының сүз башында беренче хыялының композитор булу теләге икәнлеген әйтеп үтә. Бәлки, шуңадыр да, шагыйрьнең кайбер шигъри әсәрләре үзләре үк музыка жанрына тартым булып чыккан. Мәсәлән, аның «Ноктюрн», «Элегия», «Марш», «Вальс» исемле әсәрләре бар. Шулай ук «Иренең кысма», «Мин адашкан юл», «Таба алмагач», «Яшен ташы», «Төш бүлеп» шигырьләренең жанрын ноктюрн дип билгели, «Гомер турында җиде элегия»сен яза. Р.Харисның музыкага тартылуы шигырьләре белән генә чикләнеп калмый; беренчедән, аның шигырь текстлары, поэмалары музыкаль әсәргә әверелсә, икенчедән, ул мәшһүр җырчы һәм композиторларга сүздән һәйкәл коя; өченчедән, музыкаль дөньяны анализлап, публицистик мәкаләләр яза; дүртенчедән, ун еллап мәдәният министры урынбасары булып эшләү дәверендә үзе үк сәнгать үсеше өчен өлешен кертә. Өч драматик поэмасы булуга да карамастан, шагыйрь үзенең күбрәк музыкаль театрга тартылуын таный. Юкка гына аның «Кыйссаи Йосыф» балеты, киң җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятып, матбугатта дистәләгән мәкалә чыгуга дучар булмагандыр. Шулай ук Р.Харисның композитор М.Яруллин белән берлектә татар милли сәнгатендә оратория жанрын башлап җибәрүче булуын да онытмыйк.

Табигатьтән Р.Хариска күпкырлы талант бирелгән. Шагыйрь тәрҗемәче, публицист, тәнкыйтьче булу өстенә ул әле гармунчы да. Шагыйрьнең шул исемдәге поэмасы да бар. Хәзерге вакытта ул поэма радиоспектакль рәвешендә яши бирә. Ә гармунда — автор үзе.

Шагыйрь музыка сәнгате белән генә чикләнеп калмый. Бу томда укучы аның «Шигырь язган каләм белән» дигән китабын тәшкил иткән рәсемнәре белән дә таныша алачак. Бу рәсемнәр белән шигырьләр җырдагы көй һәм сүзләр кебек үк бәйләнештә, бербөтен. Шулай ук рәсем сәнгате дә шагыйрьнең шигырь исемнәрендә үк чагылыш таба. Мәсәлән, аның бер шигыре «Кипр эскизлары» дип атала. Ә менә «Рәссам» поэмасында кеше кәефен, халәтен, кичерешләрен югалырга әзер торган мизгел итеп тасвирласа, тышкы күренешне төсләр гармониясе ярдәмендә бирә. Әсәрдә, сюжетлылыктан бигрәк, сурәт тудыру өстенрәк чыкканлыгы күренә. Өч фрагменттан торган «рәсем», тормышны хәрәкәттә күрсәтеп, мизгелләрне бербөтен итеп оештыра. Моңа өстәп, аның һәр дүрт шигыренең берсе «төсле шигырь» икәнен дә әйтү урынлы булыр. Музыка өлкәсендә ул С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, Р.Яхин, А.Ключарев, М.Яруллин, С.Садыйкова, Р.Ваһапов, И.Мәҗитов, Р.Ахиярова, И.Газиевларга сүздән һәйкәл салса, рәсем һәм сынлы сәнгать өлкәсендә Бакый Урманче, Харис Якупов, Фәридә Хәсьянова һәм Н.И.Фешинга багышлап шигырьләр яза. Шагыйрьнең 1997 елда М.Горький исемендәге музейда оештырылган күргәзмәсе Х.Якупов, Р.Шаһиевалар тарафыннан югары бәяләнә.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: шагыйрь Р.Харисның татар милли музыка һәм рәсем сәнгате өлкәсендә җитди хезмәтләре һәм үз урыны бар.

*Фәридә Хәсәнова*

*Îíûêëàðûì Ì•ðèí•, Ê•ðèì,*
*Àäåëüã• áàãûøëûéì.*

*Мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен шигырьләр*

## *Лап-лап*

Лап-лап, лап-лап,
аю килә атлап.
Бөтен төше тузан,
чәче-башы тузган.
Аюга ни булган?
Аюга ни булган?

Берни дә булмаган —
куян туп уйнаган,
тупка каты типкән,
туп очкан да киткән,
төшкән ул чокырга,
чокырда чытырман.
Аю тупны күргән,
алып менеп биргән.

## *Ботка*

Газлы зәп-зәңгәр утта
әни пешерә ботка.
Юган ярмасы — сары,
исеме була тары.
Ярманы суга салды,
суны кайнатып алды.
Сөт өстәде аннары,
тоз өстәде аннары,
май өстәде аннары,
һәм ботка булды тары.

## *Чәбәк-чәбәк*

Чәбәк-чәбәк-чәбәк,
күрдек алтын чабак.

Алтын чабак кайда?
Тыпырчына сайда.

Аны сайдан алдык,
тирән суга салдык.

Әй шатлана чабак —
чәбәк-чәбәк-чәбәк.

## *Чикерткә*

Сикер, сикер, чикерткә,
ә баланңны сикертмә —
баланңның боты кыска,
сикерә алмас оста,
җиргә егылып төшәр,
төшәр дә башын тишәр.
Ятар аннары чирләп,
чер-чер итеп черелдәп...

## Бәлли бәү

Әлли-бәлли-бәлли бәү...
Куян кечтек, Аю дәү!

Аюның бар юрганы,
ап-ак кардан сырганы.

Әлли-бәлли-бәлли бәү...
Юрган җылы, юрган дәү!

Юрган астына сыя
Аю, Төлке һәм Куян.

Аю җылы, юрган дәү...
Әлли-бәлли-бәлли бәү!

## *Йокы керде күземә*

Йокы керде күземә,
тынгы бирми үземә —
ачтыра да яптыра,
тик утырам аптырап.

Аннан керде авызга
кара син бу явызга:
ачтыра да яптыра,
һава гына каптыра.

Тагын бер тапкыр кергәч,
мин йокыны алдадым —
авызымны яптым да
кирегә чыгармадым.

Бигрәк дөрес иткәнмен —
йоклаганмын-киткәнмен...

## *Батыр малай*

Миңа өй эше күчертми —
Екканым да юк чалып.
Син булдыксыз, дигән була —
Йөри шунда кыланып.

Толымыннан тарткан өчен
Сөйләшми дә, күр әле!
Кемлегемне күрсәтермен
Очрый калса шүрәле.

Бармагын кыстырып тормам,
Мөгезеннән алырмын,
Ай-ваена карамыйча,
Иңбашыма салырмын.

Бөтен мәктәп каршысында
Колакларын борырмын.
Синең аяк асларыңа
Шүрәлене орырмын.

Бөтен кеше тел шартлатыр —
Сөйләмимен арттырып —
Мактанырсың: шушы батыр
Толымымнан тартты дип!

## *Сине көтә тыныч таң*

Кызыл канат балыклар да,
Көмеш саңак балыклар да
Әлли-бәлли бәү итә —
Алар да ялыкканнар.

Купшы башлы камышлар да,
Кыйгач кашлы камышлар да
Әлли-бәлли бәү итә —
Талгын җил, тавышланма!

Зәңгәр күзле дулкыннар да,
Серле күзле дулкыннар да
Әлли-бәлли бәү итә
Тып-тыныч упкыннарда.

Энҗе таккан тирәкләр дә,
Мәрҗән таккан тирәкләр дә
Әлли-бәлли бәү итә,
Яфрагын тибрәткәләп.

Тирәктәге сандугач та,
Каендагы карлыгач та
Әлли-бәлли бәү итә —
Уяныр таң тугач та.

Сине көткән тыныч таң да,
Уятасы матур чаң да
Әлли-бәлли бәү итә —
Дөнья йокыга талган!

## *Башмак кигәндә*

Менә безнең уң башмак,
менә безнең сул башмак.
Уңын киябез башта,
аннан киярбез сулын...
Уңын алдан кигәннең
уңа икән, ди, юлы.
Уң аяк безнең әзер.
Сулын киябез хәзер.

## *Күсе*

Күз ачкысыз буранда
Күсе чыккан урамга.
Итек, бияләй кигән,
ә шәле көрткә тигән.

Озын койрык аз гына
сыймаган шәл астына.
Койрык очы бозланган —
мин Күсене кызганам.

## *Әнием*

Әнием минем матур,
күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була,
ул өйгә кайтып кергәч.

Мин елышам әнигә,
әни миңа елыша.
Битләре аның кайнар,
ә куллары йоп-йомшак.

Конфет та кирәк түгел,
кирәк түгел курчак та,
чөнки мин әниемне
алдым инде кочаклап.

## Үчти-үчти

Үчти-үчти үчтеки,
үсте китте кечтеки.

Үсте, үсте — зур булды,
таза һәм матур булды,

акыллы, зирәк булды,
һәркемгә кирәк булды.

## *Кызыл ат*

Минем кызыл атым бар.
Аның ялы кап-кара.
Атым йөгерә алмый,
атым тәгәрәп бара.

Тояклары юк аның,
көпчәкләре генә бар.
Кап-кара көпчәкләре
дүрт аякка ике пар.

## *Капитан этәч*

Безнең авыл өстендә
тишелде болыт төбе —
бер сәгать яуды яңгыр
чиләкләп койган кебек.

Ишегалдын су басты.
Ярык имән тагарак
лапастан чыкты йөзеп,
әйтерсең лә бер кораб.

Тагаракта, кәпрәеп,
безнең яшь этәч тора.
Тагарак капитаны
«Борчак күп!» — дип кычкыра.

Тавыклар кыт-кыт килеп
йөгерешә лапаста:
— Этәчебез, коткарчы,
безне монда су баса!..

Әй гайрәтләнә этәч
күлдәвек уртасында,
тик ярдәм итми, чөнки
капитан судан курка.

## *Борчак*

Бер әтәч,
тугыз тавык
алганнар
борчак табып.

Күп күренгән
аларга—
тотынганнар
санарга.

Һәр тавык
берне алган.
Әтәч
борчаксыз калган.

Әтәч кычкырган
шулчак:
«Кайда
унынчы борчак?»

## *Нәрсә сөйлик?*

Ак болытта — ап-ак кар,
күк болытта яңгыр бар.

Ак болытта бик суык,
җылындык чаңгы шуып.

Ә күк болыт лычма су —
йөздек тә соң ичмаса!

Тирәнгә чумган идек,
болыт төбенә тидек.

Менә басып торабыз.
Нәрсә сөйлик? Сорагыз...

## *Кар кораб*

Төсле китапка карап,
кардан ясадык кораб.

Утырттык ул корабка
кар кәҗә дә, кар ат та,

кар маэмай һәм чын әтәч,
ул кигән кызыл кәпәч;

Кар бабай белән Кар кыз!
Без нишләр идек карсыз...

## *Карга*

Кар-р-р, кар-р-р,
оябызда кар бар,
йоклап булмый карда —
мин бит бала карга.
Бирегезче көрәк —
кар көрәргә кирәк!

Каркылдама, карга,
канатларың барда.
Без бит синнән аста.
Көрәк сабы кыска.
Канатларың — көрәк.
Кар көрәргә өйрәт!

## *Юмартлар*

Апамның зур курчагы
күзләрен йома белә.
Минем шаян маймылым,
эченә төртсәң, көлә.

Апамның телефоны —
өреп тутыра торган.
Минем автомобилем —
ачкычын бора торган.

Апам белән без дуслар,
уенчык алмашабыз.
Икебез дә без юмарт —
беркайчан талашмабыз.

## *Безнең өебез*

Безнең өебез биек,
тора ул күккә тиеп.

Минем бүлмәм бик якты,
ул кояшка бик якын.

Төнлә безгә туп-туры
керә йолдызлар нуры.

Ай да карый ялтырап.
Ай йолдыздан яктырак.

Лифт ватылган чакта,
өйгә менәбез атлап.

Саныйм хәзер хатасыз —
сигезенче катта без.

## *Акбай*

Арт аягына баскан,
биш-алты медаль аскан.
Сикереп бии Акбай.
Акбай — акыллы маэмай.

Койрыгын селкетә —
ул тәмле азык көтә.
Конфет ашамый Акбай.
Акбай — акыллы маэмай.

Биеде дә тирәмдә,
барып ятты чирәмгә.
Тузанга ятмый Акбай.
Акбай — акыллы маэмай.

## Алтын кала

Чиләкләп ком алабыз —
алтын кала салабыз.
Җимермибез, төзибез —
менә нинди бала без!

Бер чиләк су алабыз,
суны комга салабыз.
Су сеңде! Кая китте
безнең алтын калабыз?

## Сөенеч

Сөенеч!
Сөенеч! —
песиебез хәзер өч:
зурысы — әни песи,
икесе — бәби песи.
Бәбинең берсе ап-ак,
ә берсе — кара колак.
Агына исем — Аппак,
кара колакка — Шапшак.

## *Песи*

Песинең тәпиләре
арып йоклап китте.
Песинең койрыгы
арып йоклап китте.
Ә песинең күзләре
һаман бай-бай итми.

Песинең колаклары
арып йоклап китте.
Песинең мыеклары
арып йоклап китте.
Ә песинең күзләре
һаман бай-бай итми.

Песинең авызы да
арып йоклап китте.
Песинең борыны да
арып йоклап китте.
Күзен йомгач ук песи
үзе йоклап китте.

## *Су коенганда*

Су чәчрәттек кояшка —
булдырабыз без аны!
Болыттан да биеккә
тузгыттык су тузанын.

Су тузаны кояшта
төрле төскә төренә,
ә аннары әйләнә
салават күперенә.

Салават күпереннән
тамды төсле тамчылар...
Алар тамган урында
чәчәкләр үсеп чыгар.

## *Төсле рәсем*

Төсле рәсем ясарга
Мәдинә бик ярата:
ясый гөлгә карап та,
ясый күлгә карап та,
чуерташка карап та,
һәм кояшка карап та...
Һич уйламастан, ялгыш
килеп чыга көнбагыш!

## Әбәк

Мин кәҗәдән җитез —
йөгерәмен бик тиз.

Аны куып тоттым,
«әбәк!» диеп суктым.

Җиттем аяк белән,
суктым таяк белән.

Акайтты ул күзен,
тырпайтты мөгезен,

сакалын селекте,
мине куып китте.

Кәҗә, кәҗә, тукта,
сөзмә мине юкка,

уйныйк әйбәт кенә!
Бу бит «ӘБӘК» кенә...

## Арба

— Арбаның моторы кая?
— Әнә болында йөри.
— Шәһәр малае дигәч тә,
сөйләшмә инде юри.
Болында кызыл ат кына
йөри койрыгын болгап.
— Ә мин сиңа чынлап әйтәм:
арбаның моторы — ат!

## *Күбәләк кунак җыя*

Аллы-гөлле күбәләк
Чәчәктән табын корган,
кемне чакырыйм, диеп,
уйга батып утыра:

чикерткә каты чырлый,
энә карагы — урлый,
чебен тирескә куна —
бик әшәке ул шуңа;
озынборын, кигәвен
сиздерми кан имгәнен;
шөпшә һәм төклетура
йөдәтәләр бал сорап...

Аптыраштa күбәләк...
Киңәш бирик бергәләп!

## *Белә*

Бака баласы йөзә белә.
Кәҗә бәтие сөзә белә.
Үрмәкүч ефәк
келәмнәр тукый,
тукран черегән
агачны чукый.
Ә безнең Кәрим
нәрсәләр белә?

Ул, чәп-чәп итеп,
йөзә дә белә,
ми-ки-ки, диеп,
сөзә дә белә,
тук-тук-тук итеп,
тукый да белә,
шушы шигырьне
укый да белә.

## *Курыкмыйм*

Урманда матур алан.
Төнгә урманда калам —
зур гына шалаш корам,
шунда кереп утырам.
Тиздән, кояш баюга,
килеп җитәр аюлар.
Шалашымны күрергә
килеп җитәр бүреләр.
Кабан килеп ышкыныр,
ә пошилар пошкырыр,
ябалак чукыр аны —
мин бер дә курыкмамын.
Ә син, әти, сынап тор —
ау мылтыгыңны тотып,
шалаш башында утыр.

## Куян

Колакларың озын булса,
һәрчак уяу торырсың.

Аякларың җитез булса,
төлкедән котылырсың.

Ак туныңны чиста тотсаң,
купшы куян булырсың.

Безнең сүзләрне тыңласаң,
әйбәт куян булырсың.

## *Ике ата каз*

Яшел чирәмдә
ике ата каз...
Ярым җәелгән
каты канатлар
тонык ялтырый —
кыныдан әле
чыгып җитмәгән
явыз кылычтай.

Аларда күккә
омтылыш үлгән.

Ап-ак муеннар
сөңге сабыдай.
Алар очында
алсу томшыклар.
Әйтерсең алар
кемдер тәненә
кереп чыгарга
да өлгергәннәр.

Ә күзләрендә
кап-кара ялкын.
Һәм шушы күзләр
тишелеп китсә,
ана казларның
ак күлмәкләрен
кап-кара сөрем
каралар кебек.

Шуңа күрә дә
ап-ак болытлар,
зәп-зәңгәр һава,
ямь-яшел алан
чагыла алмый
алар күзендә.

Килеп бәрелгәч
канатка канат,
яшел аланда
яңгырады набат:
кыйгак-как-как-как,
кыйгак-как-как-как.

Бу ана казлар,
байбикәләрдәй,
яшел аланда
биеп йөрделәр,
ата казларның
«бөек» көрәшенә
куәт бирделәр.
Ә шул чагында
зәп-зәңгәр күктән
кап-кара тилгән
атылып төште.
Сары бәбкәне
күтәреп китте...
Дөресме итте?..

# *Матур өй*

(Поэма)

## 1

Гөрселдәп җиргә аугач,
ботаклардан чистаргач,
кабыгыннан арынгач,
бүрәнә булды агач.

Төз, юан бүрәнәләр
озыннар һәм авырлар...
«КамАЗ»ларга төядек,
алып кайттык авылга...

## 2

Бүрәнәләрне киртләп,
бурадык нарат бура.
Яшел чирәм өстендә
сап-сары булып тора.

Акбай йөрде йомышка —
ташып торды йомычка,
ә песи булышмады,
мыштым гына йоклады.

## 3

Авылда бүген өмә,
өмәдән калыйм димә —
өй салуның эше күп,
эш күп булгач, кеше күп.

Мүк кыстырып күтәрдек —
булмады җил үтәрлек.
Әле кыш киләсе бар,
явасы бар салкын кар...

Акбай һаман булыша —
чебиләрне куыша:
йомычка ялгыш тисә,
чебинең башын тишә.

Песи күләгә тапкан,
тагын йокларга яткан...
Песи әле кечкенә...
Эшләмичә йөргәнгә
үсә алмый һич кенә.

**4**

Җәйдек сап-сары идән:
озынлыгы ун адым,
киңлеккә дә ун адым.
Песи биеп карады,
Акбай биеп карады,
мин сикереп карадым —
шыгырдарлык булмады.

**5**

Түбәсен яптык,
кәрнизен кактык,
ишеген куйдык,
болдырын җыйдык...
Буядык...
Юндык...
Нинди матур өй булды!

— Юк, — дип әйтте дәү әти, —
әле эшләр бетмәде,
өй өй булып җитмәде.

**6**

Миңа тәрәзләр ошый —
һәрберсенең өстендә
утыра тавис кошы.

Кем кискәнне әйтимме?
Аны юкә тактадан
ясады дәү әтием!

Мин дә булыштым аңа —
һәр тәрәзгә булсын дип,
кошларны тордым санап...

**7**

Балчыктан измә издек,
кирпечкә кирпеч тездек,
түшәмгә тишек уйдык,
тишеккә торба куйдык.
Иртә иде —
кич булды,
кич булганда
мич булды.

— Песи, песи, кер әле,
яңа мичне күр әле.

Ә песи күптән мичтә,
чыгасы килми һич тә.

**8**

Беркөнне бергәләшеп
без өйне җыештырдык.
Тәрәзләргә өр-яңа
матур пәрдәләр кордык.

Төсле телевизорны
антеннага ялгагач,
Акбайга да, миңа да
бернинди эш калмагач,

дәү әтидән сорадым:
— Инде эшләр беттеме?
Өй өй булып җиттеме?

— Юк әле, — ди, — бетмәде,
өй өй булып җитмәде.

**9**

Тагын бер атна үткәч
утырттык биек капка.
Капкадан керә ала
мотоцикл да, ат та.

Хәтта иң зур машина
тими капка башына.

Ә песине күр әле,
нинди оста үрмәли!
Ул ашыга-ашыга
менде капка башына.
Менүен менде дә бит,
төшүен төшә алмый.
Куркуыннан калтырап,
елый-елый мияулый.
Песисез калабыз дип,
очкан иде котларым.
Әтием баскыч куйды...
Мин песине коткардым!

— Күр әле, — ди дәү әти, —
капкасы да, капкасы —
кунак чакырып тора
аның һәрбер тактасы!

## 10

Көз җиткәч, безнең өйдә
тагы да кызды эшләр —
дәү әнием пешерде
кош телләре, бәлешләр,

бавырсак һәм урама —
тәме чыкты урамга.
«Их, уңды!» дия-дия,
пешерде гөбәдия,
кәләвәсен, әлбәне,
тагын бик күп әллә ни!
Әни койды коймаклар...
Безгә килде кунаклар.

## 11

Сөйләштеләр, көлештеләр,
җырлаштылар, биештеләр,
«Өегез бик якты икән,
җылы булсын», — диештеләр.

Барыбыз да шатландык,
песием дә шатланды...
Аны Акбай куган иде,
миңа менеп атланды.

— Акбай, тимә песигә,
песи саклый күседән.
Песи киләсе көзгә
ярдәмче була безгә.

Акбай аңа тимәде.
Песи бер көй көйләде,
ә мин шигырь сөйләдем —
барысы да кул чапты —
кызык чыкты шулчаклы...

**12**

Иртәгәсен, уянгач,
сорадым дәү әтидән:
— Өлгердеме инде өй,
дәү әтием, әйт инде?

Дәү әти болай диде:
— Кичә өй туе үтте,
шулай булгач безнең өй
тәмам өлгереп җитте.
Син белеп кал бүгеннән —
дуслары күп өй генә
матур һәм яхшы була,
дуслары күп өй генә
җылы һәм якты була!

*Пьеса*

# *Серле алан*

*2 пәрдәле хикмәтле тамаша*

**КАТНАШАЛАР:**

Нарый.
Барый.
Карт.
Себерке.
Башмак.
Гармун.
Күсәк.
Рогатка.
Шырпы.
Ябалак.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман. Кемнәрдәндер, нәрсәдәндер кача-кача, арып-талып, ике малай йөгереп керәләр. Куып килүчеләрнең тавышлары якыная бара. Малайларның берсе агач куышына, икенчесе агачлар артына яшеренәләр. Шунда ук сынык саплы иске Себерке һәм иске, табаны авыз кебек ачылган Башмак очып керәләр.

Себерке. Тотсам — берәм-берәм
Кирәкләрен бирәм:
Сынык сабым белән,
Сынык сабым белән
Сыртларын себерәм,
Сыртларын себерәм...

Башмак. Мин — Башмак,
Мин — Башмак!
Үзем тешлимен башлап,
Үзем тешлимен башлап...

Себерке белән Башмак, тыз-быз очып, «Кайда ул юньсезләр?», «Кайда ул ялкаулар?» — дип, малайларны эзлиләр.

С е б е р к е. Кирәкләрен бирәм,
Кирәкләрен бирәм:
Сыртлары уелганчы,
Туйганчы бер себерәм,
Туйганчы бер себерәм...

Б а ш м а к. Үзем тешлимен башлап,
Үзем тешлимен башлап:
һап! һап!
һап! һап!

Себерке белән Башмак очып чыгып китәләр. Агач артыннан куркып кына бер м а л а й чыга.

Н а р ы й. Уф! Котылдым бугай!

Б а р ы й *(агач куышыннан башын чыгарып).* Киттеләрме инде? Күренмиләрме, Нарый?

Н а р ы й. Курыкма, курыкма, Барый, чык әйдә.

Б а р ы й *(куыштан чыгып).* Себерке себерәм дип өскә килә башлагач, котым ботыма ук төшеп китте. Менә шунда хәтле. *(Аягының чәнти бармагын селкетеп күрсәтә.)*

Н а р ы й. Мин дә үләм дип торам. Бигрәк тә Башмактан курыктым — тешлим, ди бит, явыз!.. Хәзер инде курыккан юк — куркыныч үтте...

Б а р ы й. Билгеле!.. Нарый, Нарый! Әйт әле, син дә кыю, мин дә бик кыю, ә нишләп качтык соң әле без авылдан? Менә хәзер күз күрмәгән, колак ишетмәгән җиргә килеп эләктек.

Н а р ы й. Качмыйча нишлисең?.. Иске табак, ярык калак, ертык башмак, тишек картуз ыргыта-ыргыта кугач... Әнә Башмак белән Себерке монда хәтле килеп җиттеләр...

Б а р ы й. Бигрәк каты куганнар инде! *(Җирдән сәләмә эшләпә күтәреп.)* Карале, сәләмә эшләпәләргә хәтле ыргытканнар. Тукта әле, Нарый, ник кудылар соң безне тиктомалга?

Н а р ы й. Ялкау, буш сүз, җилкуар, диделәр ич!

Б а р ы й. Булса соң! Ялкау беркемгә зыян да китерми, комачауламый да...

Н а р ы й. Комачаулыйсыз, диделәр ич...

Б а р ы й. Ничек? Берни дә эшләмичәме? Юкны сөйләмәсеннәр... Нәрсә дә булса эшләгәндә генә зыян китереп була. Әйтик, мәктәп бакчасына эшкә чыгып, берәр агачны сындырсак, зыян булыр иде. Фермага барып, берәр бозауны имгәтсәк, тимертомыр җыйганда берәрсенең аягына тимер төшерсәк — зыян,

кеше йоклаганда утын ярсаң, көн саен дәрескә йөреп, укытучыларны борчысаң — комачау булыр иде.

Н а р ы й. Шулай шул. Без мәктәп бакчасына өч елга бер генә мәртәбә дә чыкмадык, фермага бармадык, утын ярмадык, металлолом, макулатура, көл җыймадык, мәктәпкә дә көн саен йөрмәдек. Без бит бернәрсә дә эшләмәдек — шулай булгач, зыян да китермәгәнбездер.

Б а р ы й. Алайса ник кудылар безне?

Н а р ы й. Үземнең дә башым җитми шул. Югыйсә инде миндә акыл да *(маңгаен күрсәтә)* әнә ни киңлек!

Б а р ы й. Маңгаең киң, ә акыл миндә күбрәк.

Н а р ы й. Йә, йә, күпме соң синдә акыл?

Б а р ы й. Миндәме? Миндә... *(Тирә-ягына карана, күрәсең, чагыштырырга берәр әйбер эзли.)* Миндәге акыл кыш көне бүреккә дә сыймый, белдеңме... Ике яктан артып кала...

Н а р ы й. Акыл түгел, колаклар ич алар.

Б а р ы й. Акыл! Әти һәрвакыт: «Яле, бераз акылыңны арттырыйм!» дип, шуларны тотып тарта... Әти белә инде ул!..

Н а р ы й. Арттымы соң?

Б а р ы й. Артмас! *(Нарый Барыйның колагын тарта. Тегесе авыртудан кычкыра.)* Кая, мин дә колагыңны тартып акылыңны арттырыйм әле. *(Үзе дә Нарыйньң колагына ябышмакчы була, тегесе кача. Барый Нарый артыннан куып китә.)*

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урман аланы. Алан уртасында ап-ак бик зур шар тора. Өй зурлык ук булмаса да, мунча чаклы бар да бар. Шарның гөмбә булуы мөмкин, бәлки, ул Сәмруг кош йомыркасыдыр, йә булмаса — пәһлеван малайларның уен тупларының берседер. Һәрхәлдә тамашачы өчен кызыклы нәрсә. Куыша-куыша Н а р ы й белән Б а р ы й килеп керәләр, әүмәкләшеп сугыша башлыйлар. Шул вакыт бер яктан тавыш ишетеп туктап калалар.

Т а в ы ш. Кемнәр кычкырыша анда?.. Кемнәр ул? *(Малайлар як-якларына каранaлар, шарны күреп гаҗәпләнәләр, качмакчы булалар.)* Качмагыз, качмагыз, егетләр! Мин хәзер... таякны гына алам...

Б а р ы й. Ишеттеңме, таягымны алам да чыгам, ди...

Н а р ы й. Ишеттем шул.

Б а р ы й. Таяк белән безне кыйнарга чамалый бугай.

Н а р ы й. Таяксыз йөри алмыйдыр ул. Безне тиктомалга нишләп кыйнасын ди... Зыян да китермәдек...

Карт керә. Ул галимгә дә охшаган, сихерче-мазар булуы да бик мөмкин, бәлки, урман каравылчысы гынадыр. Ул күзләрен уа, авызын зур итеп ачып исни — бик тә йокысы килә, ахрысы... Кулында таяк, ә иңендә Ябалак утыра.

Карт *(Ябалакны шар янындагы агачка кундырып).* Егетләр, сез кайда?..

Нарый *(агач артыннан башын чыгарып).* Нәрсә, бабакай?

Барый. Мин дә монда, бабакай.

Карт. Нигә качтыгыз, егетләр?

Нарый. Без качмадык, без... без... җиләк җыя идек.

Барый. Әйе... безне әни җиләккә җибәргән иде...

Карт. Уңган-булган егетләр, ахрысы, үзегез. Кемнәр сез? Ничек бирегә килеп чыктыгыз?

Нарый. Авылдан без, авылыбызның иң шәп, иң асыл малайлары...

Барый. Безне анда уч төбендә генә йөртәләр.

Карт. Бик әйбәт! Бик әйбәт!

Нарый. Утын кисәргә дисәң — без, җырларга дисәң — без, биергә дисәң дә — без.

Барый. Телевизор төзәтергә дисәң дә без!

Нарый *(Барыйны туктатып, шыпырт кына).* Йә инде, арттырма. Син үзең кем соң, бабакай?

Барый. Әйе, үзең кем соң син, бабакай?

Нарый. Бу нинди Ябалак?

Карт. Бу бик хикмәтле Ябалак. Ул минем иң тугры ярдәмчем, иң ышанычлы таянычым.

Барый. Нинди ярдәмче дә, нинди таяныч булсын инде ул? *(Карт тирән итеп исни башлый, Ябалак-таяк каты итеп канатларын бәргәләргә тотына, малайлар яңадан качмакчы булалар.)*

Барый. Бигрәк ямьсез кычкыра икән.

Карт. Менә шундый инде ул — миңа йокыга китәргә бирми. Уяулыгым ул минем, у-я-у-л-ы-г-ы-м!

Нарый. Хикмәте шул гынамы?

Карт. Минем өчен шунысы да бик җиткән.

Барый. Куркыта гына ич ул.

Карт. Шулай куркытмаса, мин бит йоклап китәм.

Нарый. Китсәң соң, рәхәтлән, бабакай, йокла туйганчы.

Барый. Синең урында булсаммы?

Карт. Ярамый шул, ярамый, егеткәйләр...

Барый. Урманыңа ут каба мәллә, урманчы бабай?

Карт. Мин урманчы түгел... Мин...

Нарый. Ә кем соң син?

Карт. Мин... без менә шарны саклыйбыз.

Нарый. Ә нәрсә була аңа?

Карт. Ул бик кыйммәтле шар. Аңа һәрвакыт куркыныч янап тора... Аны мин менә инде әллә ничә мең ел күз йоммыйча саклыйм.

Нарый. Мең ел буе дисеңме?

Барый. Сөйләмә юкны, бабакай, мең ел буе йокламый; торып булмый. *(Исни башлый. Ябалак тагын канатларын шапылдата. Барысы да сискәнеп китәләр.)* Кара син аны — иснәргә дә ярамый...

Карт. Иснәргә ярый, йокларга ярамый. Шар харап була. Ә йокы килә, балакайлар.

Барый. Син йокла, әнә теге тоз күз үзе генә сакласын,

Карт. Юк, үзе генә саклый алмый ул. Ул мине уяу тота, ә мин шарны саклыйм.

Барый. Башка кеше сакласа ярамыймы соң?

Карт. Ярый, нишләп ярамасын! Ышанычлы кешеләр табылса бик әйбәт булыр иде дә бит... Бәлки, сез, егетләр, ярдәм итәрсез. Шундый арыдым... Бераз гына мине ял иттереп алсагыз... Тагын берничә мең ел күз карасын саклагандай саклый алыр идем...

Барый. Без дә бит, бабакай, бик ерактан килдек, арыдык, талдык, хәлсез калдык. Йә үзебез дә йоклап китәрбез.

Нарый. Чәпчемә әле, Барый, мең ел йоклаганым юк, ди бит. Йоклап алсын соң бераз.

Барый. Үзебез йоклап китсәк?

Нарый. Ә ябалак? Ярар, бабакай, бар, бераз йоклап ал.

Карт. Менә рәхмәт, менә рәхмәт! Бик әйбәт егетләр булып чыктыгыз бит әле сез! Мин алайса бераз гына... йөз генә ел... йоклап алыйм...

Барый. Тукта, тукта, бабакай, ничә ел дисең?

Карт. Йөз генә ел...

Нарый. Юк, бабакай, без моңа риза түгел.

Барый. Булмый, булмый, безгә кичкә авылга әйләнеп кайтырга кирәк.

Карт. Илле генә ел...

Барый. Булмый, булмый, илле ел йокламыйча кем түзә алсын?

Карт. Алайса бер генә ел...

Б а р ы й. Бер сәгать, бабакай. Шуннан артык секунд та юк!

К а р т. Ярар, ярар... Бер сәгать тә күп вакыт ул.

Б а р ы й. Күп шул. Мин бер дәрескә дә чак түзәм...

Н а р ы й. Чәпчемә инде, җитәр... Килештек, бабакай, бар, йокла.

К а р т. Мин киттем, булмаса.

Б а р ы й. Ә Ябалакны калдыр.

К а р т. Әлбәттә, тик карагыз аны, зинһар, йокламагыз... Ябалакның күзләре каплана күрмәсен...

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әлеге дә баягы ак шар алан уртасында. Аның янында Я б а л а к тора.

Б а р ы й. Бабакай безне төп башына утыртты, ахры.

Н а р ы й. Карт кеше нишләп безне алдасын ди инде.

Б а р ы й. Кем алып китсен дә, кем ватсын инде моны?..

Н а р ы й. Хикмәтле шар ди бит.

Б а р ы й. Нинди хикмәт, нинди сер булсын монда — менә кара.

Барый шар янына килә дә аңа кагылмакчы була. Шул вакыт кинәт Ябалак кычкырып җибәрә.

Я б а л а к. Ти-мә! Ти-мә! *(Малайлар катып калалар.)*

Н а р ы й. Тисә нәрсә була?

Б а р ы й. Нәрсә була, ә? *(Ябалак эндәшми.)* Нәрсә бәбәкләреңне ялтыратасың? *(Шарга таба сузыла. Ябалак тагы да катырак кычкырып җибәрә.)*

Я б а л а к. Ка-гыл-ма!!

Н а р ы й. Кара, кара, телләшеп маташа...

Б а р ы й. Хәзер мин сине... *(Барый кулына таяк ала да Ябалакка сукмакчы була, тик ул очып китеп икенче урынга барып куна.)* Нарый, әйдә, малай, икәүләшеп! *(Нарый белән Барый, акрын гына Ябалакка якынлашып, аңа ташланалар, тик ул яңадан очып китеп агачка куна.)* Әллә сиңа сузылып җитмәс дисеңме? Нарый, кил әле, аркаңа басыйм әле. *(Тик шул вакыт аланга тычкан баласы килеп чыга, Ябалакның күзләре ялт-йолт итә.)*

Н а р ы й. Барый, кара әле, тычкан күргәч, бу ябалак әллә нишләде... *(Ябалак Тычканга ташлана, аны тоттым гына

*дигәндә, Нарый Ябалакны тотып ала.)* Барый, бар, Ябалакны капларга берәр нәрсә алып кил. *(Барый сәләмә эшләпә табып кереп Ябалакны каплый.)*

Барый. Менә шулай була ул! Эләктеңме? Нарый, малай, кая илтик моны?

Нарый. Әнә теге агач куышына илтеп куй. *(Барый Ябалакны куышка куя.)* Әйдә тизрәк шарның серен ачыйк. Бар, шакып кара әле шуны...

Барый. Бер-бер хәл булмас микән?

Нарый. Куркак син. Алайса үзем тотынам...

Барый. Әйдә, икәүләшеп...

Нарый шарга әкрен генә сугып карый. Аланны хрусталь чыңы кебек тавыш биләп ала. Барый да шарга кагыла. Тавыш көчәя, гаҗәеп музыкага әверелә. Хрусталь чыңы, электр-музыка коралларының космик моңы, кошлар сайравы бергә кушылып әкияти гүзәл яңгыраш алалар. Боегып утырган чәчәкләр башларын калкыталар, ботаклар киерелеп куялар, күбәләкләр уйный башлыйлар, гомумән, табигатькә олы куаныч, бәхет иңә.

Нарый. Барый, миңа шундый рәхәт, шундый рәхәт!.. Әле беркайчан да болай рәхәт булганы юк иде.

Барый. Миңа да.

Нарый. Хәтта кычкырып җырлыйсым килә башлады.

Шул сүзләрне генә әйтеп бетерүе була, Нарый янына зур Гармун килеп баса да уйный башлый.

Гармун. Җырлап җибәр шәп итеп...

Нарый. Кара әле моны, ни кылана... Җырлый белмим ич мин.

Гармун *(Барыйга).* Алайса син җырлап кара.

Барый *(җырларга тырышып карый).* Юк, тамак әллә нишләгән.

Гармун. Булмаса, типтереп биеп җиб-бәрегез! *(Бию көе уйный.)*

Нарый. Минем ни... аяк авырта.

Барый. Минем биерлек хәлем юк... Ашыйсым килә.

Нарый. Эх, берәр сумса булса!

Әйтеп бетерүе була, әллә кайдан ике Сумса килеп чыга. Малайлар сумсаларга сузылалар. Сумсалар читкә тайпылалар. Малайлар аларны куып йөриләр...

Нарый. Эх, берәр ат булса! Атланып алыр идем, куып тотар идем дә, кабып йотар идем.

Кинәт Нарый каршысына гүзәл А й г ы р килеп баса һәм кешнәп җибәрә.

Тпру! Тпру! *(Атланмакчы була, ләкин уңышсыз.)* Барый, син атлан...

Б а р ы й *(атланырга маташа, ләкин булдыра алмый).* Булмый миннән — аяк авырта. *(Сумсалар да, айгыр да юкка чыгалар.)*

Г а р м у н. Эх, сез, пешмәгән мәми авызлар. Җырла, дидем — җырлый белмәдегез... Бие, дидем — бии белмәдегез. Ат булды — атлана алмадыгыз. Азык булды — ашый алмадыгыз... Чын ир-егетләр утка керәләр, сулар кичәләр, ә үз дигәннәрен итәләр. Сез әзергә бәзер дә яши белмисез икән, әрәмтамаклар. *(Гармун да юкка чыга, шар сүнә.)*

Н а р ы й. Кара әле, бу шар сүнгәч, бөтен шатлык юкка чыкты бит әле. Ни булды инде бу, ә?

Б а р ы й. Әйе, шундый да рәхәт иде!..

Н а р ы й. Тукта әле, шар тылсымлы булып чыга бит болай булгач! Ул кешегә шатлык китерә ала икән ләбаса...

Б а р ы й. Әйтәм аны бабакай күз йоммыйча да саклаган. Әйтәм аны...

Н а р ы й. Т-с-с-с!.. Шаулама! *(Ян-якларына карана, күрәсең, берәр нәрсәдән куркадыр.)*

Б а р ы й *(пышылдап кына).* Нәрсә булган?

Н а р ы й. Башыма бер уй килеп маташа.

Б а р ы й. Ә минем башка ике уй килеп маташа.

Н а р ы й. Нәкъ минеке кебектер әле...

Б а р ы й. Йә, әйт әле, нинди уй килде синең башыңа?

Н а р ы й. Бу шарны... авылга тәгәрәтеп кайтабыз да...

Б а р ы й. Ватабызмы?

Н а р ы й. ...авыл халкына бәхет өләшәбез!

Б а р ы й. Карале, Нарый, минем башыма да нәкъ менә шундый, нәкъ менә шундый уй килгән иде бит.

Н а р ы й. Тәгәрәтеп алып кайтабыз, авыл уртасында туктатабыз, авызга бармак тыгып бер сызгырабыз... Менә шулай итеп. *(Сызгырып карый — булдыра алмый.)*

Б а р ы й. Һәй, шулай сызгыралар ди! Менә ничек сызгыралар аны. *(Авызына ике кулын да тыгып сызгырмакчы була, ләкин бусыннан да фш-ш-ш-ш кына чыга.)*

Н а р ы й. Мактанчык!

Б а р ы й. Мин юри генә сызгырмадым, бабакайны уятырмын дип курыктым. Авылга кайткач сызгырып күрсәтермен әле, бөтен авыл җыелыр... Ә җыелгач нишлибез?

Н а р ы й. Халык алдында башта мин чыгыш ясыйм. Нотык!

Сез, дип әйтәм, безне, авылның иң акыллы, иң уңган, иң булган малайларын — хаксыз рәвештә куып җибәрдегез. Безнең керсез намусыбызга тап төшердегез — ялкаулар, җилкуарлар, әрәмтамаклар дип хурладыгыз. Андый закон юк!

Б а р ы й *(оратор позасында).* Юк андый закон! Иске башмаклар, ертык картузлар, тишек бияләйләр ыргыттыгыз безнең өстебезгә. Ә без...

Н а р ы й. Ә без сезне... кечелекле рәвештә гафу итәбез. Алай гына да түгел, без сезгә мәңгелек бәхет, бетмәс-төкәнмәс шатлык бүләк итәбез. Без саран түгел. Бүгеннән башлап...

Б а р ы й. ...бүгеннән башлап сез эшләмичә генә ашап ята алачаксыз. Мәктәпкә йөреп азапланырга да кирәк булмас... Мороженое ашап, телевизордан гел мультфильмнар гына карап яшәячәкбез... Нарый, безгә, малай, һәйкәл куярлар микән?

Н а р ы й. Әйттең сүз, билгеле, куярга тиешләр!

Б а р ы й. Икебезгә бернеме, әллә аерым-аерым куйдырыйкмы?

Н а р ы й. Икебезгә бер дә җитә. Икене ясарга вакыт күп кирәк...

Б а р ы й. Алай булгач, каравылчы бабай уянганчы әйдә, тәгәрәтә башлыйк.

Н а р ы й. Ябалакның эшләпәсе төшәрлек түгелме? Бер картны алдаганнан берни дә булмас! Башладык!

Нарый белән Барый шарны авыл ягына таба этә башлыйлар. Гүзәл музыка агыла башлый. Менә шар әкрен генә кузгала. Тырыша торгач, малайлар шарны тәмам урыныннан кузгаталар. Кузгатулары була, дөбердәп-шатырдап, малайларның икесен ике якка ыргытып, җир астыннан к а п - к а р а ш а р килеп чыга.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Алан уртасында и к е ш а р: берсе — ак, икенчесе — к а р а. Ак шар артыннан Н а р ы й күренә.

Н а р ы й. Барый, син кая? Барый, дим! А-у! А-у!

Б а р ы й *(кайдандыр тавышы ишетелә).* Кычкырма инде, күтәреп торгыз. Шундый курыктым, шундый курыктым, малай. Карале, тезләрем ничек дерелдиләр...

Н а р ы й. Дерелдәсеннәр сәнә. Кара әле. *(Кара шарны күр-*

*сәтә.)* Әйдә, тизрәк, бабакай уянганчы шатлык шарын авылга алып кайтып китик.

Б а р ы й. Мин куркам... Әнә теге кара шардан...

Н а р ы й. Таптың куркыр нәрсә, шундый ук шар инде ул, бераз каралган гына.

Б а р ы й. Булыр сиңа!..

Н а р ы й. Ышанмыйсыңмы? Менә кара!

Нарый кара шар янына килә, шарга орына — тавыш-фәлән юк. Нарый шарга чиертеп карый, тавыш юк. Йодрыгы белән суга. Кайдандыр ерактан, әллә урман артыннан, әллә җир астыннан, әллә шар эченнән күк гөлдерәгән кебек тавыш ишетелә.

Н а р ы й. Әйтәм бит — буш!

Нарый киерелеп торып тагын бер суга — тавыш көчәя. Җил сызгырган, тау ишелгән, бүре улаган, агачлар сынган тавышлар дәһшәтле музыкага әвереләләр.

Б а р ы й. Булыр сиңа буш!

Тавыш көчәйгәннән-көчәя бара. Агачларның ботаклары салынып төшә. Гөлләр башларын ияләр, күк йөзен шәмәхә соры төсләр каплап ала. Малайларның йөзләре чытыла, кәефләре китә...

Н а р ы й. Әллә нәрсә булды әле миңа.

Б а р ы й. Миңа да... Бар нәрсәне җимерәсе, ватасы, яндырасы килә.

Әйтеп бетерүе була, малайлар алдында К ү с ә к, Р о г а т к а һәм Ш ы р п ы кабы пәйда була.

Б а р ы й. Э-э-э-х! Ут төртәм урманына — янсын! *(Шырпыга тотынмакчы була.)*

Н а р ы й. Син нишлисең, җүләр?! Үзебез дә янып үләбез ич!

Б а р ы й. Ярар, кабызмыйм. *(Шырпы югала.)* Алайса менә бу карачкыны атып үтерәм, тормасын күз көеге булып. *(Рогатканы алмакчы була.)*

Н а р ы й. Ябалакны кычкыртып каравылчыны уятмакчы буласыңмы? Аннары шатлык шарын ничек алып китәбез?

Б а р ы й. Атмыйм алайса. *(Рогатка да югала.)* Җимерәм, кырам, чәлпәрәмә китерәм дөньясын... *(Күсәккә тотына. Күсәк, Барыйны сөйрәп, Нарыйга сугарга дип килә башлый. Нарый кача, Күсәк аны куып йөри...)*

Н а р ы й. Ташла тизрәк... Ташла, дим...

Б а р ы й. Сөйри бит, ычкынып булмый...

Күсәк, әйләнеп-тулганып, Нарыйга китереп ора да, эшеннән канәгать булып, юкка чыга.

Б а р ы й. Нарый! Нарый! Син исән-саумы?.. Ник эндәшмисең? *(Шыңшый башлый.)* Менә бәла! Сугып үтердем, ахрысы, иң якын, иң әйбәт дусымны... Нарый, дим!

Н а р ы й. Уф-уф!.. Янбашым!.. Үтерә яздың ич, юньсез... Нәрсә булды соң әле бу безгә, ни эшләдек без? *(Кара шарга күзе төшеп.)* Тукта әле, хикмәте бу кара шарда түгел микән?

Б а р ы й. Әйе, әйе...

Н а р ы й. Бу шар beləсеңме нәрсә булып чыкты?

Б а р ы й. Кайгы шары, ахрысы...

Н а р ы й. Кайгыныкы шул менә... Минем башыма тагын бер шәп уй килде.

Б а р ы й. Нинди?

Н а р ы й. Әллә мин әйтәм, кайгы шарын авылга алып кайтып, бөтен авылны кыйнатабызмы?

Б а р ы й. Юк, юк! Теге Күсәк, чыгып, икебезне дә тукмап ташласа?..

Н а р ы й. Шулай шул. Шатлык шарын гына алып кайтыйк.

Б а р ы й. Вакыт үтә, әйдә, тизрәк тәгәрәтә башлыйк.

Малайлар ак шарны әкрен генә тәгәрәтә башлыйлар. Аркалары, иңнәре белән этәләр, башлары белән төртәләр, егылалар, торалар... Аланнан тәгәрәтеп чыгып киттек дигәндә генә Барый кычкырып җибәрә.

Б а р ы й. Карале, карале, Нарый! *(Карасалар, кайгы шары шатлык шары артыннан тәгәрәп килә ләбаса!)*

Н а р ы й. Пшал! Пшал! Явыз!

Б а р ы й. Прәс! Прәс! *(Шар килүен дәвам итә.)*

Н а р ы й. Әйдә, анысын яңадан урынына илтеп куябыз...

Малайлар кара шарны зур авырлык белән кире тәгәрәтә башлыйлар. Шарны куйдык дигәндә генә Барый тагын ачыш ясый.

Б а р ы й. Карале, кара! Хәзер бусы тәгәри — болар берсе берсенә береккәннәр, ахрысы.

Н а р ы й. Юк сүз сөйлисең син, нишләп берексеннәр ди.

Б а р ы й. Юк, алар береккәннәр!

Н а р ы й. Шулай да булсын ди. Астына берәр нәрсә кыстыргач, тәгәри алмас. Кыстыр, әйдә... *(Барый ак шар астына түмәр кыстыра.)* Анысына түгел, монысына кыстыр. Менә шулай...

Б а р ы й. Тотындыкмы?

Н а р ы й. Тотындык... *(Ак шарны тәгәрәтәләр, карасалар, кара шар да урынына таба тәгәри. Кара шарны кире урынына тәгәрәтәләр, ак шар да аның артыннан тәгәри.)*

Б а р ы й. Булмады бу болай.

Н а р ы й. Ни эшләргә соң? *(Бераз уйланып торгач.)* Болай итәбез! Син хәзер кара шарны урманга илтеп адаштыр. Мин ак шарны авылга тәгәрәтәм...

Б а р ы й. Киттек... *(Кара шарга тотынмакчы гына була да, яңадан Нарый янына йөгереп килә.)* Юк инде, юк! Син мине алдарга чамалыйсың.

Н а р ы й. Нинди алдау ул тагын! Син бит минем иң якын дустым...

Б а р ы й. Дус булсаң, бар, әнә кара шарны үзең тәгәрәт, ә мин — ак шарны... дустым!

Н а р ы й. Барыбер түгелмени? *(Кара шарга тотынмакчы гына була — Барый янына йөгереп килә.)* Ә-ә! Хәйләкәр төлке!..

Б а р ы й. Тукта әле, тукта, тукта, дим...

Н а р ы й. Кара син аны, мин урманда кайгы шарын адаштырып йөргәндә, берүзе шатлык шарын авылга алып кайтмакчы булган бит, ә!..

Б а р ы й. Йә, шуннан ни була?

Н а р ы й. Авыл халкы синең үзеңә генә һәйкәл куя — менә ни була! Ә мине ялкау, уңмаган дип авылга да кертмәүләре бар. Кайгы шарын адаштырып йөргәнемне минем кем белер?

Б а р ы й. Мин белгәч җитмәгәнмени сиңа?.. Мин бит аны бөтенесенә сөйлим...

Н а р ы й. Сиңа кем ышансын!.. Иң яхшысы — шобага салу. Таяк табып килик тә...

Икесе ике якка китеп, таяклар алалар, тиз-тиз үзләре генә шобага тотып карыйлар. «Мин өскә чыгам!», «Мин отам!» дип, алан уртасына йөгереп киләләр.

Н а р ы й. Минем таяк шомарак, минеке белән тотыйк!

Б а р ы й. Минеке җайлырак!

Н а р ы й. Минеке әйбәтрәк!

Б а р ы й. Юк, минеке шәбрәк... *(Малайлар чак тукмашмый калалар.)*

Н а р ы й. Булмый болай...

Б а р ы й. Нишлибез соң?

Нарый. Санашабыз.

Барый. Мин башлап саныйм. *(Күккә карап.)* Бер, ике... Тугыз...

Нарый. Шулай саныйлармыни, тинтәк. Болай саныйлар аны:

Әке, бәке,
Сынык пәке,
Аксак-туксак,
Барабан корсак,
Җепсез орчык,
Чәүкә, чыпчык,
Син кал, Мин — чык.

Менә мин чыктым. Сиңа кара шар калды.

Барый. Дөрес түгел. Яңадан сана... үзеңнән башлап.

Нарый *(саный).* Менә яңадан мин чыктым... Хәзер ризамы инде?

Барый. Риза инде, риза...

Нарый. Алайса, әйдә тизрәк... бабакай уянганчы...

Нарый ак шарны авыл ягына, Барый кара шарны урман ягына таба тәгәрәтеп китәләр. Аланның кырыйларына якынлашкан саен, шарлар ныграк каршылык күрсәтәләр...

Барый. Нарый, дим, Нарый! Ишетәсеңме мине?

Нарый. Нәрсә?

Барый. Әллә болай интекмикме, малай...

Нарый. Ник алай дисең?

Барый. Әллә, мин әйтәм, авылга кайтарып азапланмыйкмы ул шарны?..

Нарый. Ә һәйкәл?

Барый. Һәйкәле дә кирәкмәс... Аннары, нәрсәгә безнең авылга моның хәтле шатлык? Безне мәсхәрәләп куып чыгардылар үзләре, ә без аларга шатлык алып кайтыйкмы?

Нарый. Шушында калдырыйкмыни инде?..

Барый. Шарны да монда калдырыйк, үзебез дә монда гына калыйк... Әнә каравылчыга әллә ничә мең елга җиткән. Безгә дә берәр мең елга җитәр әле, башкаларга бирмичә генә тотсак.

Нарый. Шулай шул, әйдә, ташлыйк та, башта бераз ял итик.

Малайлар икесе берьюлы шарларын ташлыйлар да алан уртасына киләләр. Шарлар алан кырыенда чайкалышып торалар да әкрен генә алан уртасына таба тәгәри башлыйлар. Алар бер-берсенә якынлашкан саен, сирена тавышына охшаш тавыш көчәя бара. Шул вакыт өйдән Карт килеп чыга да тизрәк ике шар арасына ташлана. Аларга бәрелешергә ирек бирми.

Карт *(кычкыра).* Нишләдегез сез, юньсезләр? Нишләттегез шарларны? *(Шарлар һаман Картны кыса баралар. Картның куллары йомшый, шарлар, куркыныч тавыш чыгарып, якынлаша баралар.)* Бәрелешәләр бит! Бәрелешәләр, ярдәм итегез! Нәрсә карап торасыз?

Бары й. Бәрелешсәләр соң! Без арыдык.

Нары й. Берни дә булмас, янбашлары гына бераз яньчелер шунда...

Карт. Алар бәрелешсәләр, коточкыч шартлау була. Ишетәсезме? Нишләп карап торасыз — булышыгыз!

Малайлар тиз-тиз Карт янына йөгерешеп киләләр һәм, шарларны аерып, Картны коткаралар...

Карт. Уф!.. Чак харап булмый калдык... Үзебез дә харап була идек. Җир йөзендә дә тынычлык бетә иде... Шундый ышанган идем мин сезгә, шундый ышанган идем...

Нары й. Соң без бит синең ышанычыңны акладык, бабакай, шарны югалтмадык... Ватмадык та...

Бары й. Әнә әле тагын берне таптык...

Карт. Мин бит сезгә шатлык, бәхет шарын ышанып калдырган идем, ә сез Җир өстенә кайгы шарын да чыгаргансыз... Ябалакның күзен каплап... *(Ябалак күзеннән эшләпәне алып ташлый.)* Ул бит уяулык!.. Ишетәсезме: У-я-у-лык! Шатлыкны, бәхетне саклаганда, һәрвакыт уяу булырга кирәк. Кайгыны мин шатлык белән бастырып куйган идем... Шатлык елдан-ел ныгый иде, анда кошлар, күбәләкләр килеп куналар иде, таң җилләре, яңгырлар, карлар кагылалар иде. Шулай итеп алар шатлыкны Җир буйлап тараталар иде... Ә хәзер шул кошлар, шул күбәләкләр кайгы шарына кунсалар, аңа җилләр, яңгыркарлар кагылсалар, Җир йөзендә кайгы-хәсрәт артачак... Сез менә нишләдегез... уяулыкның күзен томалап...

Нары й. Безне нишләтәсең инде, бабакай?

Бары й. Хәзер нишлибез инде, ә, бабакай? *(Малайлар шыңшый башлыйлар.)*

К а р т. Елап дөньяны бәладән коткарып булмый... Бәхет, шатлык артсын дисәк, җиң сызганып эшләргә кирәк... Әйдәгез, кайгы шарын яңадан күмәргә булышыгыз!.. Сезне нишләтергә икәнен аннары уйларбыз...

Малайлар, кайгының кара шарын элекке урынына күмеп, өстеннән шатлык шары белән бастырып куялар.

Уеннан уймак чыгарып бөтен тормышыбызны харап итә язганыгызны аңладыгызмы инде?

Н а р ы й.

Б а р ы й. Аңладык... Аңладык... Аңладык...

К а р т. Ә хәзер шатлык шарын күз карасы кебек сакларга кирәк. Бу безнең төп бурычыбыз: уяулык кошы Ябалакның да, тынычлык күгәрченнәренең дә, сезнең дә, дуслар!

П ә р д ә.

# Либреттолар

# *Ватан-ана уллары*

(Оратория)

## I. Бул тыныч *(пролог)*

Илем җире,
Илем күге,
Илем суы,
Булыгыз тыныч —
Ватан-ананың кулында
Мәңге уяу изге кылыч!
Туган илем,
Бул тыныч!

Иген шаулар,
Кошлар сайрар,
Чиста булыр суларың —
Төрән кебек без мәңге тырыш,
Кылыч кебек без мәңге уяу —
Ватан-ана уллары.

## II. Яу кырында

Ирләр хоры:

Илгә дошманнар кергәч,
Кулга корал алдык без.
Катыйль канын агызып,
Үзебез пакь калдык без.

Хатыннар хоры:

Катыйль канын агызып,
Үзегез пакь калдыгыз.
Гасырлар каршысында
Хаклы була алдыгыз!

И р л ә р  х о р ы:

Илгә дошманнар кергәч,
Яу кырына киттек без.
Юлбасар оясының
Нигезен көл иттек без.

Х а т ы н н а р  х о р ы:

Юлбасар оясының
Нигезен көл иттегез.
Илебезнең юлына
Мәңгелек гөл сиптегез!

Х о р:

Гөл-чәчәктә илебезнең юллары.
Сезгә рәхмәт,
Сезгә рәхмәт,
Ватан-ана уллары!

## III. Кайттылар

Туган илне яратулары
Үлемнән дә көчлерәк булганнары
Кайттылар.
Тыныч таңнар,
Елмаюлар булып
Кайттылар.
Исемнәрегез һәрчак телдә,
Батырлар!

Туган илне яратулары
Яшәүдән дә көчлерәк булганнары
Кайттылар.
Кайттылар да
Стеналардагы
Буш рамнарга керделәр.

Исемнәрегез догаларда,
Батырлар!

### IV. Ана

Бу чәчләрем минем ап-ак кар,
Ак чәчләргә кунган бар моң-зар.
Нигә кирәк Җиргә сугышлар?
Сугышканда Җирдә сулыш тар.

Тыныч булсын барлык аналар.
Кан коймасын безнең балалар.
Таммаса да Җиргә алсу кан,
Пешәләр ич алсу алмалар,
Күтәрелә ап-ак калалар,
Ал гөлләргә чума далалар.
Таммаса да Җиргә алсу кан,
Алсу булып ата Җирдә таң!

Күз төбемә баткан сырларым —
Улларымның киткән юллары...
Бу чәчләрем минем ап-ак кар.
Бетсен,
Бетсен Җирдә сугышлар!

### V. Кирәк булса

Иңнәргә рюкзак асып,
Яшел вагонга басып,
Егетләр, кызлар китә...
Алтын кояшлы иртә...

Т а в ы ш л а р:

Шулхәтле рәхәт җанга —
Китеп барабыз БАМга.

Аерылабыз бик азга —
Очрашырбыз КамАЗда.
Биш-алты көн дигәндә,
Хат алырсыз Төмәннән.

Сау булыгыз... Көтәбез...
Сагынырбыз... Китәбез...

Хор:

Алтын кояшлы иртә.
Егетләр, кызлар китә.
Кирәк булганда кабат
Алар — мәңгелек солдат!

## VI. Синең сакта

Илем күге,
Илем җире,
Илем суы,
Булыгыз тыныч —
Улларыгызның кулында
Корыч чүкеч,
Зирәк каләм,
Уяу кылыч.

Кырларың гөрләр,
Кешеләр җырлар,
Тыныч атар һәр таң —
Без
Синең сакта,
Ватан!

# Ак сөлгегә мәдхия

*(Вокаль-симфоник поэма)*

**1**

И ак сөлге! Сине зурлыйм
хак сүз белән:
кунак килсә, каршыладың
ак йөз белән;
дошман килсә, чыкмадың
кулын юарга
һәм булмадың ак төстәге
сатлык байрак!
И ак сөлге, беркайчан да
пычранмадың —
күпме сөрттең син халкымның
тирен, канын!
Канатлы җырга әйләнсен
ихтирамым,
канатлы җырга әйләнсен
ихтирамым!

**2**

Тукыдылар сине, сөлге, көчле куллар,
агарттылар сине, сөлге, ташкын сулар...
Син көрәштең сабантуйда — билгә яттың:
батырларның гаделлеге, көче артты.
Син ямь бирдең олы туйлар пар атына,
әверелеп туйның бәхет канатына.
Төшсәң иде чигешләреңнең серенә! —
һәр бизәгең тирән мәгънәгә төренгән...

**3**

Яу-сугышка озатып калдың
син ирләрне,
«Сау бул!» диеп, кулга кушылып
җилфердәдең.

Каршы алдың исән кайта
алганнарын,
төсе булдың яу кырында
калганнарның...
Җеназада син, ак сөлге,
безнең кулда —
озатасың гүр иясен
соңгы юлга...
Кабер дымы һәм күз яше
авырлыгын
күтәрергә син бирәсең
сабырлыкны!

**4**

Кичрешләрнең таныш сиңа һәркайсы,
илемнең һәр куанычы, кайгысы.
И ак сөлге, халкым җаны төсле син —
ак сөттән сеңгән пакьлекнең көзгесе!
Һәр эшнең —
ниятнең өмете — уңыш...
Кешенең хыялы матур!
Кешеләрнең өмете зур!
Кешеләрнең эшләре күп!
И ак сөлге!
И пакь сөлге —
булыш, булыш!

**5**

И ак сөлге! Син бүген дә
минем кулда.
Үзем исә халкым баскан
олы юлдан,
авыр юлдан, данлы юлдан
алга атлыйм,
заманның хәтәр җиленнән
сине саклыйм,

син бит байрак — ә байракны
саклау тиеш,
җилфердәтеп тоткан килеш,
чиста килеш!
Һәм мин атлыйм мирасымның
хакын хаклап —
әбиемнән калган сөлге
нинди ап-ак!
Ак!.. Пакь!..
Ак!.. Пакь!..

# *Казан*

(Оратория)

## I. Җыр башы

Сөйләүче:

Казан, Казан!
Син — кунакчыл йортым минем,
Син — горурлыгым чишмәсе,
Бәхетемнең нигез ташы,
Җырымның башы,
Мәгърур Казан!

Соло:

Син — горурлыгым чишмәсе...

Дуэт:

Бәхетебез нигез ташы...

Хор:

Назлы җырлар башы,
Моңлы җырлар башы,
Дәртле җырлар башы —
Мәгърур Казан!

Синең аша кичкән гасырлар —
Олы тарихта олы эзләр.
Бөек кешеләр,
Әкияти эшләр,
Зур ачышлар,
Тиңсез шатлыклар эзе синдә,
Шанлы Казан!

Актыр башың,
Олыдыр яшең,
Ныктыр нигезең,
Нурлыдыр йөзең,
Татарстанымның башкаласы
Казан, Казан!

## II. Легенда

Хатын-кызлар хоры:

Борма, борма, борма су,
Киек казлар йөзгән су.
Ярларына ак ташлар,
Төнбоеклар тезгән су.
Илнең кырык батыры,
Кайтып килгәндә аудан,
Бормалы су буенда
Ял итәргә тукталган.

Аларның арасында
Егетләр кебек батыр,
Камыш кебек төз буйлы,
Тулган Ай кебек матур
Кыз бала...

Кыз бала:

Су алам дип сузылган идем,
Төште-китте алтын казан
Минем талган кулымнан.

Ирләр хоры:

Төшкән-киткән алтын казан
Аның талган кулыннан...

Ыруыбыз казаны,
Бәхетебез казаны
Төшкән-киткән, төшкән-киткән
Аның талган кулыннан...

Чумып карарга кирәк,
Эзләп табарга кирәк.
Казан кайда — бәхет шунда!
Казан кайда — бәхет шунда!

Хатын-кызлар хоры:

Чумганнар, эзләгәннәр,
Атна, ай эзләгәннәр,
Күп еллар эзләгәннәр.
Төзегәннәр куышлар,
Аннары агач өйләр,
Аннары таш биналар.
Һәм калыккан зур кальга —
Казан дигән таш кала.

Күмәк хор:

Һәм калыккан зур кальга —
Нигезе алтын таш кала.
Яшә, яшә, таш кала,
Казан дигән башкала!

## III. Көрәшкә озату

Егетләр хоры:

Без Казаннан чыккан чакта
Күтәрелде томаннар...

Казан (хатын-кызлар хоры):

Мәскәү иле белән бергә
Тевтоннарның башын ташка
Бәреп ватыгыз, оланнар.

Егетләр хоры:

Пугачевка ярдәм кирәк —
Без китәбез, туганнар...

К а з а н:

Пугачевка ул булыгыз,
Кылыч тоткан кул булыгыз,
Сынатмагыз, оланнар!

Е г е т л ә р   х о р ы:

Наполеон гаскәрләре
Мәскәүгә тотынганнар...

К а з а н:

Мәркәзне коткарышыгыз!
Беләкләрегез талмасын,
Сау булыгыз, оланнар!

С ө й л ә ү ч е:

Яу булып килүчеләрнең
Тиз төкәнде юллары.
Ил уллары белән бергә
Булды Казан уллары,
Кышкы Сарайны алганда,
Нарва, Псков янында,
Азин, Чапай отрядында
һәм Курск дугасында.
Мулланур була белделәр,
Газинур була белделәр,
Җәлил була белделәр...
Бергәләшеп рейхстагка
Кызыл байрак элделәр.

Х о р:

Без Казаннан чыккан чакта,
Чәчәк күмде юлларны.
Ил өчен утка керергә,
Ил өчен диңгез кичәргә
Әзер,
Һәрвакытта әзер
Без, Казанның уллары!

## IV. Сходка

Төркемнән тавыш:

Сходкага! Сходкага!

Трио:

Сходкага! Сходкага! Сходкага!

Хор:

Сходкага! Сходкага! Сходкага!
Мөмкин түгел кысылып яшәү —
Университет казарма кебек.
Кысыла тән,
Кыерсытыла җан,
Чикләнә аң богау устав белән.
Һәр тәрәзә — полиция күзе,
Һәрбер ишек — жандармерия колагы!
Иркен итеп тын алырга
Ирек кирәк студентларга,
Ирек кирәк кешеләргә,
Ирек кирәк Россиягә!..

Инспектор:

Таралыгыз!
Таралыгыз яхшы чакта...

Хор:

Ирек кирәк,
Ирек кирәк Россиягә!..

Инспектор:

Таралыгыз,
Таралыгыз яхшы чакта...
Күрмисезме —
Алдыгызда биек дивар!

С о л о *(В.Ульянов):*

Әйе, дивар.
Ләкин черек,
Төртсәң — ава!

Х о р:

Әйе, ава.
Черек стена
Төртсәң — ава.

«Аврора» залпы аударды аны
Мәңгелеккә.
Яшь Ульяновның сүзләре
Раска чыкты,
Раска чыкты.

### V. Мәңгелек ут

Х о р:

Казан уртасында мәңгелек ут
Яна, яна, яна, яна.
Казан күгендә, ялкын булып,
Каһарманнар хатирәсе дулкынлана.

Х а т ы н - к ы з  т а в ы ш ы:

Сез Совет власте хакына
Һәлак булдыгыз, каһарманнар:
Мулланур Вахитов...
Роман Петров...
Камил Якуб...
Мартын Межлаук...
Исемнәре билгесезләр...
Йөзләр...
Меңнәр...

Сезнең ялкынланган хатирәгездән
Җылылык ала,
Яктылык ала
Безнең көннәр.

Хор:

Казан уртасында мәңгелек ут
Яна, яна, яна, яна...

## VI. Хезмәт каласы

Горур тора мәгърур Казан
Баһадир су ярында.
Атом чоры хәрәкәте
Казан урамнарында.

Йөгерә «ЛАЗ»лар, «МАЗ»лар,
«ПАЗ»лар, «ЗИЛ»лар, «УАЗ»лар,
Гаҗәеп зур «БелАЗ»лар,
Һәм төяп кирпеч, бетон,
Торба, ашлык һәм шатлык,
Безнең көчле «КамАЗ»лар.
Туктамагыз,
Чабыгыз —
Төзелешле чагыбыз.
Э-эх!
Төзелешле чагыбыз.

Шаулый Казан, гөрли Казан,
Урамнар бәхет тулы.
Мең дә бер һөнәргә ия
Казан эшчесе кулы.

Самолетлар, чәкчәкләр,
Пыяладан чәчәкләр,
Компрессорлар, көпчәкләр,

Кетгут, сабын, вертолет,
Приборларның төрлесе —
Һич санап бетергесез.
Эшчеләре
Казанның
Хезмәттә дан казанды.
Э-эх!
Хезмәттә дан казанды.

### VII. Мәдхия

Ачык йөзле калам син,
Киң күңелле калам син,
Үткер сүзле калам син,
Тәмле телле калам син,
Әй Казан син, Казан син,
Иң бәхетле балаң мин!

Алып кебек батыр син,
Алтынчәчтәй и матур син,
Идел кебек горур син,
Мәңге шулай булырсың,
Әй Казан син, Казан син,
Иң бәхетле балаң мин!

Илле милләт өе син,
Ничә халык көе син,
Дуслыктыр нигез ташың,
Бәхет булсын юлдашың,
Әй Казан син, Казан син,
Татарстанымның башкаласы
Мәгърур Казан!

# *Кеше*

*(Оратория)*

## I. Җир һәм Кеше

Кешенең иң олы байлыгы — Җир.
Җирнең иң олы байлыгы — Кеше.
Гүзәл мәхәббәт
Һәм изге тугрылык
Бәйләсен һәрчак
Кешене Җиргә!
Мәңгелек данга
Тиенсен Кешенең
Җирне Җир иткән
Һәрбер эше!

## II. Прометей

Хакыйкать:

Син, Кеше, хәлсез булып тудың,
Кояш баткач, салкыннарда туңдың,
Караңгылык котыңны алды,
Син яшенгә,
Син Кояшка табындың.

Хор:

Хәлсез булып тудың —
Син яшенгә,
Син Кояшка табындың.

Хакыйкать:

Илаһи ут,
Бөек яшен!
Сезсез ката
Күздә яшем, —
Дип ялвардың.

Җир сыкрады синең өчен,
Аннан әйтте:
Үзеңне бәхетле итәргә,
Мине якты, җылы итәргә,
Кеше, җитәрме көчең?

Хор:

Җирне якты, җылы итәргә,
Үзеңне бәхетле итәргә,
Кеше, җитәрме көчең?

Прометей:

А... а... а... а...
Мин — Прометей.
Көчем җитте —
Кешеләргә,
Учыма төяп,
Кояш уты илттем.
Ә үземнең йөрәгемне
Чукый, чукый каракош.
Әрнесәм дә, күңелем рәхәттә —
Җир җылынды,
Җир яктырды мәңге-мәңгегә.
Кеше үзе кеше өчен
Әверелде тәңрегә.

### III. Революция. Ленин

Миллионнар тудылар
Бу дөньяга.
Миллионнар киттеләр
Бу дөньядан.

Берәүләр талады,
Меңәүләр елады
Билләрен бөгеп лә,
Кан-яшьләр түгеп лә.

Меңәүләр үстерде
Алмалар һәм ашлык.

Берәүләр яшәде
Йоклап, ашап.

Меңәүләр тешләрен
Кыса төштеләр.
Йодрыклар төйнәлде —
Тудылар көчлеләр.

Х о р:

Туды Ленин
Прометей булып.
Сузды Ленин
Ал байрак-кулын.
Меңәүләр тордылар,
Меңәүләр бастылар —
Тетрәнде Җирнең
Өсте дә, асты да.
Берәүләр кадалды —
Бетте эше.
Меңәүләр кол иде,
Меңәүләр — Кеше.

Х а к ы й к а т ь:

Ярты планетада
Билләр турайды.
Ярты планетаның
Йөзе матурайды.
Ярты планетада
Шатлык, көлү.
Ярты планетада
Шаулап чәчәк ата
Бәхет гөле.

## IV. Хезмәт

Йортка җан кертүче ташчы без,
Кирпечне кояшка манчыйбыз.
Булган-булсын,
Шәп булсын,
Җылы һәм бик җай булсын,

Булсын пөхтә һәм тигез —
Кеше шатлансын, дибез.

Эх-ма!
Сал шулай,
Тигезлә — каушама.
Илне төзү,
Җирне бизәү
Йорт салудан башлана!

Җылылык хуҗасы — монтер без,
Өйләргә яктылык бирәбез.
Булган-булсын,
Шәп булсын,
Яктырып, балкып торсын,
Җем-җем итсен һәр төше —
Җырлап яшәсен Кеше!

Эх-ма!
Тот шулай,
Тот рәтләп — каушама!
Илне төзү,
Җирне бизәү
Йорт салудан башлана.

## V. Ана

Тудың якты дөньяга —
Якты булып үс, балам.
Басар җирең җып-җылы,
Чиста сулаган һаваң.

Тудың якты дөньяга,
Чиста сулаган һаваң.
Төн җитә дип курыкма —
Төн булса да якты ул.
Тыныч таң тудыручы
Җылы Кояш яклы ул.

Төн җитә дип курыкма —
Җылы Кояш яклы ул.

## VI. Сугыш. Муса

Хор:

Кем уйлаган,
Кемнәр тапкан
Җирдә шартлау,
Җирдә суеш?
Без тудырган
Гүзәллекне
Көл итә бит
Каһәр сугыш,
Каһәр сугыш.

Хакыйкать:

О, Прометей!
Син изге диеп
Китергән утта
Җир гүзәллеге
Чыга бит юкка.

Бахның каберен
Бомба көл итте,
Шагыйрь Мусаны
Сугыш тоткын итте.

Мәрмәр Венера
Канга буялды,
Винчи сабые
Куркып уянды...

Хор:

Җир чакыра
Безнең хакка —
Без дә басыйк
Җир хакына!
Басыйк сафка
Кеше хакына!
Басыйк сафка —
Җир чакыра!

Хакыйкать:

Һәр кешедә
Бөек көч туды.
Һәрбер кеше
Прометей булды.
Чөнки Кеше
Җырга сусады —
Сугышны җиңде
Җыры Мусаның.
Җыр җиңде —
Кешенең
Тормыш җырына сусавы!

### VII. Кешегә дан!

Кешенең иң олы байлыгы — Җир.
Җирнең иң олы байлыгы — Кеше.
Гүзәл мәхәббәт
Һәм изге тугрылык
Бәйләсен һәрчак
Кешене Җиргә!
Мәңгелек данга
Тиенсен Кешенең
Җирне Җир иткән
Һәрбер эше!
Кешенең иң олы байлыгы — Җир.
Җирнең иң олы байлыгы — Кеше!

# *Кеше һәм машина*

(*Оратория*)

## I. Яңа тизлек

Безнең чор бу —
Тәгәрмәчләргә җан өргән
Бөек кешеләр чоры.
Безнең җыр бу —
Машиналарга дан биргән
Бөек кешеләр җыры!
        Хәрәкәт шуышкан,
        Хәрәкәт атлаган,
        Кешеләр атларга,
        Филләргә атланган,
        Кешеләр каекта,
        Салларда акканнар,
        Кешеләр бәхеткә
        Йөз тотып чапканнар.
        Гасырлар чапканнар,
        Дәверләр чапканнар...
        Кешеләр тәгәрмәч,
        Тәгәрмәч тапканнар.
Безнең чор бу —
Тәгәрмәчкә җан өргән чор,
Бөек кешеләр чоры.
Безнең җыр бу —
Чорыбызга яңа тизлек
Биргән кешеләр җыры!

## II. Олы максат

Сөйләүче:

Машиналарга дан җырлау
Урынлы микән хәзер —
Алар чәчәк төяргә дә,
Бомба төяргә дә әзер...

Хор:

Шикләнү һәрчак ансат...

С ө й л ә ү ч е:

Кеше — даһи, ул — баһадир...
Әмма ләкин ахыр чиктә
Үзе тапкан машинаның
Кара колы булып китсә...

Х о р:

Шикләнү һәрчак ансат...
Ә безнең олы максат...

С ө й л ә ү ч е:

Җирнең өстен, астын, суны,
Һаваны машина басса...

Х о р:

Шикләнү һәрчак ансат.
Ә безнең олы максат —
Бәхеткә тизрәк җитү,
Җирне бәхетле итү.

Д у э т:

Ни кылса да кешеләр,
Бәхеткә дип эшлиләр.
Кешеләрнең бар көче
Шул изге максат өчен.
Табигать хуҗасы дигән
Исемне аклар өчен,
Җир-суны саклар өчен,
Ватанны яклар өчен.

Х о р:

Икеләнү бик ансат,
Ә безнең олы максат —
Бәхеткә бару тизлеген
Нияткә таман итү.

### III. КамАЗ

С о л и с т:

Нияткә таман итик дип
Максатка бару тизлеген,
Күз дә ачкысыз буранда
Салдык без КамАЗ нигезен.

Х о р:

Машиналар йөгерер кыр буйлап,
Машиналар йөгерер Җир буйлап,
Бүгенгедән киләчәккә
Гүзәллек ташый-ташый,
Машиналар йөгерер чор буйлап,
Машиналар йөгерер җыр буйлап.

С о л и с т:

Хыялга таман итик дип
Төзедек без зур заводлар.
Бүгенге көн кешесе дә,
Оныклар да безне хуплар.

Х о р:

Машиналар йөгерсен кыр буйлап,
Машиналар йөгерсен Җир буйлап,
Ил-халыклар арасында
Дуслык юлы сала-сала,
Машиналар йөгерсен чор буйлап,
Машиналар йөгерсен җыр буйлап.

С о л и с т:

Өметкә таман итик дип
Чыгардык без машиналар.
Бәхеткә тизрәк илтик дип,
Машиналар ашыгалар.

Х о р:

Машиналар йөгерә кыр буйлап,
Машиналар йөгерә Җир буйлап,
Ватаныбыз нигезенә
Корыч ныклык өсти-өсти,
Машиналар йөгерә чор буйлап,
Машиналар йөгерә җыр буйлап.

**IV. Хуш киләсез!**

С ө й л ә ү ч е:

Илдә һәр көн күпме кеше
Күченә яңа йортка.
Менә без дә килеп җиттек, —
Шофер, машинаң туктат.

Х о р:

Хуш киләсез,
Хуш киләсез,
Хуш киләсез,
Хуш киләсез!..

С о л и с т к а:

Яңа йортлар нинди шәп!
Илебезгә,
хөкүмәткә,
Төзүчеләргә рәхмәт!

С о л и с т:

Килеп җиттек бик рәхәт!
Юлларга да,
Урамга да,
Машиналарга да рәхмәт!

Х о р:

Илебезгә,
Хөкүмәткә,
Төзүчеләргә рәхмәт!

Юлларга да,
Урамга да,
Машинага да рәхмәт!

Д у э т:

Рәхим итегез безгә,
Өр-яңа өебезгә.
Җырларбыз, биербез дә,
Уйнарбыз, көләрбез дә,
Сезгә теләк шул бездән —
Бу шатлык күчсен сезгә.

Х о р һ ә м с о л и с т л а р:

Бу шатлык күчсен сезгә,
Бу шатлык күчсен сезгә,
Бу шатлык күчсен сезгә,
Бу шатлык күчсен сезгә.

С ө й л ә ү ч е:

Күпме гаилә күчenә,
Ә без туктап торабыз.
Илне куандырасы бар, —
Шофер, машинаң кабыз!

### V. Хәерле юл

Ашлык төяп чаба машиналар,
Ил йомышын үтәп,
Беләбез.
Хәерле юл теләгез аларга,
Хәерле юл,
Хәерле юл теләгез!

Кирпеч төяп чаба машиналар,
Яңа өйләр кирәк,
Беләбез.
Хәерле юл теләгез аларга,
Хәерле юл,
Хәерле юл теләгез!

Чәчәк төяп чаба машиналар,
Бәйрәм өчен кирәк,
Беләбез.
Хәерле юл теләгез аларга,
Хәерле юл,
Хәерле юл теләгез!

## VI. Шофер турында баллада

Солистка:

Минем иркәм шофер иде,
Унсигездән мине сөйде.
Туйларга биш көн калганда,
Өстенә ул шинель киде.
Илне дошманнан саклады,
Мине афәттән яклады.
Җиңүгә биш көн калганда,
Мина өстендә шартлады...
Машинасы ярчыклары
Тиде минем язмышыма.

Хатын-кызлар хоры:

Безнең язмышка да тиде,
Безнең язмышка да тиде...

Бөтен хор:

Үтеп еллар, юллар аша
Безнең язмышка да тиде...

Хордан тавышлар:

Абыем үлеме иде...
Дустым иде...
Яшьтәш иде...

Хор:

Үтеп еллар, юллар аша
Ул безгә дә килеп тиде...

С о л и с т к а:

Унсигездән мине сөйде...
Ул бар иде... Ул юк инде...

## VII. Җыр-һәйкәл

Бу җыр безнең
Сугышларда шәһит киткән
Шоферлар һәм машиналарга
Хатирә булып яңгырасын.

Бу җыр безнең
Берлингача барып җиткән
Шоферлар һәм машиналарга
Мәдхия булып яңгырасын.

Бу җыр безнең тайгаларны
Иңләп үткән
Шоферларга һәм машиналарга
Рәхмәт булып яңгырасын.

Бу  җыр безнең җиңүдән
Җиңүгә илткән чорга яңа тизлек биргән,
Дәвер буе һәйкәл көткән
Барлык, барлык шоферларга,
Барлык, барлык машиналарга
Һәйкәл булсын! Һәйкәл булсын!
Һәйкәл булсын! Һәйкәл булсын!
Һәйкәл булсын!

# *Татарстан*

*(Кантата)*

Казан, Казан,
Ямаш, Тукай, Ленин каласы!
Синнән башлана гүзәл Татарстан.

Телисең икән —
бер гөл булып шытам күкрәгеңдә,
телисең икән —
йолдыз булып кабынам күгеңдә,
тик һаман да син гүзәл бул,
тик һаман син исән бул!

Безнең әти-абыйлар
синең хакка үлгәннәр;
Газинурдай батырлар
тереләй утка кергәннәр;
Җәлилләр һәм Алишлар
дарны ватып атканнар;
җыр булып кайтканнар,
синдә без яшәсен дип,
Татарстан!
Синдә без шат яшәсен дип,
Татарстан!

# *Идел*

(*Кантата*)

**1**

Идел, Идел!
Бөек данлы Идел!
Ярларыңа назлап кагасың —
халыкларга уртак язмыш булып,
син бәхеткә таба агасың.
Гасырларны суытмыйча тота
ярларыңның тирән хәтере,
чорыбызның кайнар канында да
дулкыннарың кебек ул тере.
Синең аша күпме давыл узды...
Суларыңа сеңде көек тәм...
Ә ярыңда һаман туа торды
дөнья сокланырлык бөекләр.
Идел, Идел!
Күпме халыкларның
язмышлары булып агасың.
Син
чал тарих кебек
бик борынгы
һәм киләчәк кебек
яңа син!

**2**

Сокланмыйча мөмкинме соң
сиңа, Идел-елгабыз:
рухыбызда синең көчең,
ашкынулы юлда без.
Син бөек ватандарларча
эшлисең-тырышасың:
илбасарларны кырыштың,
тынычлык корышасың.
Яктыртасың, җылытасың,
кырларны сугарасың.
Син халыклар белән бергә
киләчәккә барасың.

Синең көчле агымында
заманабыз чагыла.
Без яшибез синең, Идел,
иң-иң матур чагында.

Ярларыңда гөлбакчалар,
акчарлаклар — суыңда,
Ай, Кояш, ГЭСлар, шәһәрләр
дулкыныңда юына.

Сокланмыйча мөмкинме соң?! —
язмыш та син,
юл да син,
кырыс та син,
назлы да син,
Идел — туганлык елгасы!

**3**

Баш иябез сиңа, тугры тотып,
халыкларның уртак йоласын.
Яшә, Идел, яшә, Идел, яшә,
туганлык һәм дуслык елгасы!

# *Совет Армиясе маршы*

*(Кантата)*

*Салих Сәйдәшев маршына*

**1**

Байрагыбыз безнең кандай изге.
Байрагыбыз кояштай югары.
Дәшкәч бөек Ватан,
кыю һәм нык атлап,
җиңеп үттек,
җиңеп үттек без
авыр юлларны.

Максатыбыз безнең сөттәй изге.
Максатыбыз байрактай югары.
Илнең һәр ягында
иминлек сагында
һәрчак уяу,
һәрчак уяу без —
Ватан уллары,
һәрчак уяу без —
Ватан уллары.

**2**

Тудык без, үстек без
революцион көрәштә,
данлы көрәштә,
данлы көрәштә.

Корычтай ныгыдык
Ватан өчен көрәштә,
канлы көрәштә,
канлы көрәштә.

Байрагыбыз безнең кандай изге.
Байрагыбыз кояштай югары.

Дәшкәч бөек Ватан,
кыю һәм нык атлап,
җиңеп үттек, җиңеп үттек без
авыр юлларны.

**3**

Янартаулар кебек дулап,
куркыталмас безне утлар.
Зилзиләләр кебек улап,
чигендерә алмас сулар,
чөнки дөрес безнең юллар,
чөнки изге безнең уйлар.
Дөрес безнең юллар,
изге безнең уйлар,
якты хыяллар!

Халыклар өметен аклап,
Җирдә тынычлыкны яклап,
без атлыйбыз кырлар буйлап,
без атлыйбыз җырлар җырлап.
Ватан биргән корал көчле,
безнең ныклык ышанычлы.
Тынычлык сагында,
тынычлык сагында
совет солдаты!

**4**

Байрагыбыз безнең кандай изге.
Максатыбыз байрактай югары.
Без бәхет ягында,
тынычлык сагында!
Уяу бул син,
һәрчак уяу бул,
совет солдаты,
һәрчак уяу бул, совет солдаты!

## Нефтьчеләр

*(Ода)*

I

Нур өстенә нурлар өстәп
илдә кара алтын чыга.
Әлмәт, Баку, Төмән, Сибай,
Мангышлактан алтынчылар.

Җир шарының үзәгенә кадәр
юллар салдылар алар.
Девон көчен
Кояш яктысына
Ялгый алдылар алар —
саф күңелле осталар!

II

Ватанның абруе зурдан —
барлык илләр исәпләшә.
Кара алтынга да бәйле
Җирдә сугышларсыз яшәү?

Җир шарының үзәгенә кадәр
юллар салдылар алар.
Девон көчен
Ватан куәтенә
ялгый алдылар алар —
саф күңелле осталар!

III

Мең рәхмәткә лаеклылар
кара алтын табучылар —
ил бәхете китабына
сүнмәс сүзләр язучылар!

Җир шарының үзәгенә кадәр
юллар салдылар алар.
Девон көчен
йөрәк җылысына
ялгый алдылар алар —
саф күңелле осталар!

## Яшә, Мәскәү

*(Ода)*

Саумы, Мәскәү, безнең бөек башкалабыз!
Сиңа атап без мәдхия башкарабыз.

Катлам-катлам гасырларда нигез ташын,
мәңгелеккә төбәлүле йолдыз-башың!

Җир шарының һәр ягында синең яктың!
Синең якты— бар халыклар бәхете яклы!

Саумы, Мәскәү, безнең горур башкалабыз!
Сиңа атап без мәдхия башкарабыз.

Бөек эшләр шаһиты син, көрәшче син,
азатлык даулаучыларга киңәшче син.

Син саклыйсың йөрәгеңдә Ленин көчен.
Ленин көче — бар халыклар бәхете өчен!

Саумы, Мәскәү, киң күңелле башкалабыз!
Сиңа атап без мәдхия башкарабыз.

Тынычлыкның мәңге уяу терәге син,
чорның бәхет диеп типкән йөрәге син.

Халыкларга син сузасың дуслык кулың —
синең кулың — тынычлыкның олы юлы!

Илләр дәшә сиңа, заман дәшә:
яшә, данлы Мәскәү,
яшә, шанлы Мәскәү! Яшә, яшә!

# *Дуслык юлы*

*(Ода)*

**1**

Безне сезгә алып килде
дуслык дигән якты юллар.
Бу юлларны күп гасырлар
төзегәннәр көчле куллар.

Алып килдек сезгә сәлам,
алып килдек иң җылы сүз —
исәнмесез, якын дуслар,
исәнмесез,
исәнмесез!

**2**

Кырларыгыз пөхтә, матур,
Күңелегез җырга гашыйк.
Һәр тәрәзә чакырып тора,
һәрбер капка безгә ачык.

Һәрбер өең безгә суза
ак сөлгедә ап-ак калач —
туганнарча каршы алдың,
туганнарча,
туганнарча!

**3**

Кунакчыллык тантанасы —
сезнең бию, безнең бию!
Килеп кенә тора көе —
безгә сезнең бию көе,
сезгә безнең бию көе!

**4**

Безне сезгә алып килде
дуслык дигән якты юллар.
Бу юлларны күп гасырлар
төзегәннәр көчле куллар.

Кешеләрне, халыкларны
ерагайта алмый ара —
ныгый бара дуслык юлы,
ныгый бара,
ныгый бара!

## *Көрешербез әле*

Хисләремә ялкын кабынган,
өметләрем канат кагына.
Күрешербез әле,
сөйләшербез әле,
кайчан да булса, кайда да булса —
бер күрешү үзе мең шифа.

Юк иде лә шулай сагынган,
юк иде лә болай талпынган.
Күрешербез әле,
сөйләшербез әле,
кайчан да булса, кайда да булса —
бер күрешү үзе мең шифа.

Эзебезне еллар күммәгән,
давыл узган — ялкын сүнмәгән.
Күрешербез әле,
сөйләшербез әле,
кайчан да булса, кайда да булса —
бер күрешү үзе мең шифа.

## *Гашыйк ич мин сиңа* *

Гашыйк ич мин сиңа,
гашыйк ич мин,
чәчләремә карлар кунса да,
күзләремә сеңгән
сүнмәс яшьлек төсем
кояш, яңгырлардан уңса да.

Гашыйк ич мин сиңа,
йөрәгемдә
беркем кагылмаган хисләр бар.
Күзләремдә минем,
бәлки, син күрерсең:
уңмый торган җете төсләр бар.

Гашыйк ич мин сиңа,
күрмисеңме?
Керфекләрең генә күтәр син —
тик бер генә язга
моңлы күңелемне
чәчәк тулы бакча итәрсең.

* Âàðèàíò. 139 áèòíå êàðà.

## *Кәгазь көймә*

Шарлавыкта
кәгазь көймә
бөтерелеп
агып килә,
үзе җитез,
үзе актыр —
бәлки, миңа
сәлам-хаттыр.

Кәгазь көймә, кәгазь көймә,
кәгазь көймә,
кемнән килдең, кемнән килдең —
сөйлә, сөйлә!

Сумы шулай
уйный-көлә —
тылсымлы чың
ишетелә.
Көймәдәге
ак чатырга
мине шулай
кем чакыра?

Кәгазь көймә, кәгазь көймә,
кәгазь көймә,
кемнән килдең, кемнән килдең —
сөйлә, сөйлә!

Кердем, йөрдем
көймәдә мин,
күрдем нәрсә
төялгәнен.
Алып кала
алдым бары
балачагым
хыялларын.

Кәгазь көймә, кәгазь көймә,
кәгазь көймә,
кайдан килдең, кайдан килдең —
сөйлә, сөйлә!

Шарлавыкта —
кәгазь көймә.
Син аңарга,
зинһар, тимә.
Исән-имин
ага бирсен —
бала чагын
һәркем күрсен!

Кәгазь көймә, кәгазь көймә,
кәгазь көймә,
кайдан килдең, кайдан килдең —
зинһар, сөйлә!

## Биш канатлы кар чәчәк

Очалар кар бөртекләре —
аларны кем санасын!
Шулай еллар үтә тора,
менә килде яңасы.
Кар чәчәкләр арасында
биш канатлы бер чәчәк.
Җырлый-җырлый каршылагыз —
ел бәхет китерәчәк!

Йолдызлардан көмеш нурлар
явасы да явасы!
Шулай еллар ага тора,
менә килде яңасы.
Кар чәчәкләр арасында
биш канатлы бер чәчәк.
Җырлый-җырлый каршылагыз —
ел бәхет китерәчәк!
Безгә гаҗәеп күңелле,
ләкин бераз ямансу —
тагын бер ел үтеп китте,
менә килде яңасы.
Кар чәчәкләр арасында
биш канатлы бер чәчәк.
Җырлый-җырлый каршылагыз —
ел бәхет китерәчәк!

## *Кама аланы*

Биек ярдан Кама суы
күренеп тора.
Мин, Камадан куәт алып,
зур шәһәр корам.
Күрәсезме, күрәсезме
Кама Аланын? —
акчарлаклар канатыннан
аклык ала ул.
Матур калам, якты калам,
Кама Аланым,
гомерлеккә сиңа гашыйк
булып каламын!
Кама суы буйларында
зәңгәр урманнар.
Урманнарга сандугачлар
оя корганнар.
Күрәсезме, күрәсезме
Кама Аланын? —
сандугач сайравын тыңлап
тынып калган ул!
Матур калам, якты калам,
Кама Аланым,
гомерлеккә сиңа гашыйк
булып каламын!
Кама өстендә тылсымлы
бер йолдыз яна,
минем шәһәрем гаҗәеп
нур өсти аңа.
Күрәсезме, күрәсезме
Кама Аланын? —
йолдызларга да якты нур
өсти ала ул!
Матур калам, якты калам,
Кама Аланым,
гомерлеккә сиңа гашыйк
булып каламын!

## *Кояш вальсы*

*Салих Сәйдәшевнең мәшһүр вальсына*

I

Көн уяна, ил коена
кояш нурында.
Алтын нурлар ямь өстиләр
минем җырыма.

Ул яңгырый кырлар буйлап,
күкләргә аша,
тургайның дәртле моңына
барып тоташа.

Көн уяна, ил коена
кояш нурында.
Алтын нурлар ямь өстиләр
минем җырыма.

Яфракларда сикерешә
чыклар сәйләне...
Бар табигать минем белән
бии, әйләнә.

II

Кояшның шифалы нурын
күрү — мең бәхет!
Кояш кагылган юлларда
йөрү— мең бәхет!

Кояшның җылысы тула
безнең кочакка.
Яшәүнең кадере арта,
дуслар, шул чакта.

### III

Кояш нуры яклы без —
тынычлыкны саклыйбыз.

Саклыйбыз гөлләр өчен,
урманнар, кырлар өчен;

ашлыклы кырлар өчен,
шатлыклы җырлар өчен —

тынычлыкны саклыйбыз,
кояш нуры яклы без!

### IV

Көн уяна, ил коена
кояш нурында.
Алтын нурлар ямь өстиләр
минем җырыма.

Табигать җырны күтәрә
мәгърур хор сыман.
Җир шары үзе әйләнә
кояш вальсына!..

## *Казан утлары*

Очраштык Казан-су буйларында.
Талгын су талларны агыза.
Тын кичнең яменә тылсым өстәп,
Казаным утларын кабыза.

Без генәмени ул Казан-суга
иң татлы яшьләрен тамызган?!
Һәрвакыт бәхеткә юл күрсәтеп,
Казаным утларын кабыза.

Без тагын Казан-су буйларында.
Талгын су елларны агызган.
Кемнәрдер кичәнә тылсым өстәп,
Казаным утларын кабыза.

Казан утлары,
Казан утлары!
Сез шаһит,
сез шаһит —
йөрәкләргә
кадалды мәхәббәт уклары.

## *Игенче җыры*

Игенченең кулларында
бәхет дигән чәчүлек.
Ватанымның кырларына
беткәч алар чәчелеп,
яңгыр яуса — бодай ява,
кар яуса — арыш ява.
Игенченең күңеленә
бармыни зуррак дәва!

Ватанымның кырларына
ямь-яшел шытым чыга.
Шытымны шатлык итәләр
игенче-тылсымчылар.
Кырда күкрәп бодай үсә,
арыш та күкрәп үсә.
Игенчегә нинди шатлык,
шундый кырларда йөрсә!

Илемнең һәрбер өенә
бәхет агыла кырдан.
Алтын кырлар бушап калгач,
тагын яңгырый җырлар:
яңгыр яуса — бодай ява,
кар яуса — арыш ява.
Игенченең күңеленә
бармыни зуррак дәва!

## *Кар сулары*

Сагындыра,
кар сулары булып гөрләп аккан,
сине тапкан бәхетле яз
сагындыра.
Нигә, нигә кабат минем хәтеремә
кар сулары кагылдылар?
Кар сулары кагылдылар?..

Әллә алар
сеңмиләрме кара җиргә?
Чишмәләргә нигә алар агылмыйлар?
Нигә, нигә кабат минем хәтеремә
кар сулары,
кар сулары,
кар сулары кагылдылар?

Инде гомер җәем аша үтеп барам.
Күз алдымда һаман моңлы чагың тора,
Сагындыра,
кар сулары булып гөрләп аккан,
сине тапкан
һәм югалткан
моңлы язым
сагындыра!

## *Тавышыңны яратам*

Акыллы сүзләр эзләмә,
табып, җилгә таратма —
ни дә булса сөйлә генә —
тавышыңны яратам!

Мин аңларлык хәлдә түгел...
Күзләремә кара да,
сөйлә,
сөйлә,
сөйлә генә —
тавышыңны яратам!

Назлы сүзләр дә эзләмә,
ялкын өрмә ярама —
ни дә булса сөйлә генә —
тавышыңны яратам.

Тынычландырма да мине —
күз яшемне яңартма...
Сөйлә,
сөйлә,
сөйлә генә —
тавышыңны яратам!

## *Калам янында*

Китсәм дә, мин калам янында
бер хатирә булып, сер булып,
ахыры юк моңлы җыр булып,
язны көткән карлы кыр булып,
күз төбеңә яткан сыр булып —
бер хатирә булып, сер булып.

Китсәм дә, мин калам янында
меңнәр арасында үз булып,
күзләреңә баккан күз булып,
иң тылсымлы җылы сүз булып,
кыш катыш җәй, язлы көз булып,
күз төбеңә яткан эз булып —
меңнәр арасында үз булып.
Китсәм дә, мин
калам янында...

## Гашыйк кеше көчлерәк

Эзләдем дә таптым сине —
каршыңда басып торам.
Ник эзләдең, дип сорама,
ничек таптың, дип сора.

Талпынган чакта йөрәк,
барлык-барлык тылсымчыдан
гашыйк кеше көчлерәк,
гашыйк кеше көчлерәк,
гашыйк кеше көчлерәк!

Киез Каз Юлларында мин
адашам диеп торам.
Ник алдың, диеп сорама,
ничек кайттың, дип сора.

Талпынган чакта йөрәк
барлык-барлык тылсымчыдан
гашыйк кеше көчлерәк,
гашыйк кеше көчлерәк,
гашыйк кеше көчлерәк!

Йолдызлардан нур алганда
янып үләм дип торам.
Ник алдың, диеп сорама,
ничек түздең, дип сора.

Талпынган чакта йөрәк,
барлык-барлык тылсымчыдан
гашыйк кеше көчлерәк,
гашыйк кеше көчлерәк,
гашыйк кеше көчлерәк!

## Уйлама

Ни булды күңелгә Иделдә? —
Яңадан дулкыннар уяна...
Йолдызым суларга төште дә,
мәңгегә сүнде, дип уйлама,
уйлама,
уйлама,
уйлама,
Уйлама, онытты бу, диеп, —
белмичә Иделне буйлама.
Мәхәббәт йолдызың дулкында,
ә дулкын эчендә ул яна,
ул яна,
ул яна,
ул яна,
Ул яна, җылыта, яктырта,
рәт кертә болганган дөньяма.
Мәгънәсез вакытлы очрашу
була, дип беркайчан уйлама,
уйлама,
уйлама,
уйлама,
уйлама,
уйлама,
уйлама,
уйлама...

## *Миңа син кирәк*

Яшьлекне искә төшереп
шаулый да яшел тирәк,
еллар аша сиңа дәшәм:
кил, кил,
тизрәк кил —
миңа син кирәк!

Тирәкнең шавы күкрәктә,
сагынып сызлый йөрәк.
Еллар аша ишетәм күк:
кил, кил,
тизрәк кил —
миңа син кирәк!

Яфрак очыра беләсең,
тирәк, очарга өйрәт —
еллар аша бәхет дәшә:
кил, кил,
тизрәк кил —
миңа син кирәк!

## *Зәңгәр бозлар*

Яшьлегемнең язгы ташкынында
мәңге кайтмаска дип агып киткән
зәңгәр бозлар, зәңгәр бозлар, зәңгәр бозлар
зәңгәр бозлар гына булмаганнар...
Шул бозларның зәңгәрлеге күңелемдә
мәңге сызлар, ахры, мәңге сызлар!

Яшьлегемнең язгы ташкынында
җилбәзәк җил булып бөтерелгән
гади кызлар, гади кызлар, гади кызлар
гади кызлар гына булмаганнар...
Шул кызларның хатирәсе күңелемдә
мәңге сызлар, ахры, мәңге сызлар!

Яшьлегемнең язгы ташкыныннан
күңелемә күчкән бар сызлаулар
бәлки, узар, бәлки, узар, бәлки, узар,
бәлки, узар, дидем, бәлки, узар...
Хәзер әйтәм — алар минем күңелемдә
мәңге сызлар инде, мәңге сызлар!

## *Ак кәгазь*

Тәрәздә зәңгәр төн.
Өстәлдә ак кәгазь.
Каләмем яз төсле карада.
Мин сиңа омтылам,
мин сиңа ашкынам,
мин сине өзелеп яратам.

Тәрәздә алсу таң.
Өстәлдә ак кәгазь.
Каләмем җәй төсле карада.
Мин сине чакырам,
мин сиңа ялварам,
мин сине өзелеп яратам.

Тәрәздә якты көн.
Өстәлдә ак кәгазь.
Каләмем көз төсле карада.
Мин сине юксынам,
мин сине сагынам,
мин сине өзелеп яратам.

Тәрәздә сүрән кич.
Өстәлдә ак кәгазь.
Каләмем кыш төсле карада.
Мин сиңа яңа яз
китерерлек итеп
тагы да өзелеп яратам.

# *Юатма*

Бүген көчле яңгыр булыр сыман —
тик торганда күздән яшь килә.
Болытларны узып явармын күк,
назлы итеп ялгыш дәш кенә.

Кырыслыкка тарта бүген күңел —
из(е)рәүдән кача горурлык.
Горурлыгын сакламаса, кеше
язмышында куя борылып.

Бер рәнҗеттең икән — юатма да,
болытка бир явып эрергә...
Аяз чакта гына йөрәгемә
назлы сүзләр балкып керерләр.

## *Өч кыз*

Өч кыз урманга чыккан,
өч кыз өч якка киткән.
Төш үткән дә, кич җиткән.
Аерылышкан аланга
җыелганнар өч кыз да.

Беренчесенең уңышы —
тырыс тулы кура җиләк.

Икенчесенең уңышы —
җир җиләге тулы чиләк.

Өченчесенең уңышы —
ике кыңгырау чәчәк:
сүз куешкан аланда
егете бүләк иткән...

## *Озакладым*

Киттең инде,
күзләремнән күптән киттең инде.
Кычкырып әйткән сүзләремнән
киттең инде.
Йөрәгемне эчтән бикле, тыштан бикле,
мәңге бикле буш бер зиндан иттең инде.
Кем коткарыр,
синнән көчле кем табылыр,
кем соң ватар йөрәгемнең йозакларын?
Үтә көннәр, йозакларга тутык өстәп...
Озакладың коткаручым,
озакладың.

## *Бер генә сүз*

Бер генә сүз,
бер генә сүз әйтә алмый калдым,
таба алмый калдым вакытын.
Очып киткән кошлар төркеменә
иярмәс тә иде,
иярмәс тә иде бәхетем...

Мин ул сүзне пышылдап та әйтмәм,
мин ул сүзне җырыма да кертмәм,
мин ул сүзне йөрәгемдә йөртәм
сиңа гына диеп,
сиңа гына диеп
йөртәм, иркәм.

Бер генә сүз,
бер генә сүз әйтә алмый калдым,
табалмадым җаен-вакытын...
Кем уйлаган — шулай кечкенәдән
тора диеп,
тора диеп кеше бәхете...

## *Зәңгәр томан*

Күзләремдә нурлар кими сыман,
нурсыз кала кебек җырларымда сүзләр.
Әй, сөеклем,
синең хисең минем өчен әле һаман зәңгәр томан,
зәңгәр томан,
зәңгәр томан —
и өметле билгесезлек —
тизрәк ачыл,
тизрәк үзгәр.
Аяз көн бул —
яктырып китсен йөрәгемнең чоңгыллары.
Юкка чыксын барлык шигем, борчуларым.
Нурлар кайтсын күзләремә,
сүзләремә кайтсын нурлар...
Синең өчен яшим бары,
сөйгән ярым!

## *Нәрсә әйтим?*

Кавышуларга безнең бөтен дөнья шаһит,
вәгъдәләрне бөтен дөнья белә.
Нәрсә булды сиңа? —
оныт, диден.
Зиһенем җуеп,
оныта алмый кайтып киләм.

Нәрсә әйтим сине көткән бусагага?
Хәлләремне ничек итеп мин аңлатыйм?
Нәрсә әйтим ак каенга, тулган Айга,
йолдызларга, үз-үземә нәрсә әйтим?

Онытырмын, дисәм,
булыр ялган.
Онытмам, дип,
һич тә әйтә алмам.
Мәңге язмыш белән килешә алмам,
ничек кенә сабырлыклы була алыйм?

## *Җирдә бер кояш*

Йөз куя дөнья
кояш нурына —
әйдәгез җырлыйк
кояш турында:
кояш — безнең йөздә,
кояш — безнең күздә,
кояш — безнең сүздә, дуслар!

Һава сафлыгы
яшьләр кулында —
әйдәгез җырлыйк
һава турында:
һава шул ук миңа,
һава шул ук сиңа,
һава шул ук безгә, яшьләр!

Җир гүзәллеге
бердәм булуда —
әйдәгез җырлыйк
без Җир турында:
Җирдә бер үк кояш,
Җирдә бер үк һава,
Җирдә бер үк яшьләр, дуслар!

Хәзер тын калыйк
шушы урында —
тынлык сөйләсен
теләк турында:
Синең теләк — дуслык,
минем теләк — дуслык,
безнең терәк — дуслык, яшьләр!

## *Татарстаным минем*

Син безне тудырдың, үстердең,
тик сиңа бурычлы мәңге без.
Юк бит ул тагын бер синдәй җир —
язың — яз!
Җәең — җәй!
    Êšçå• — êšç!
Язың — яз!
Җәең — җәй!
Көзең — көз!

Көч бирдең, дәрт бирдең, рух бирдең —
улларың-кызларың — баһадир.
Сокланмый мөмкинме соң сиңа —
суың — су!
Күгең — күк!
Җирең — җир!
Суың — су!
Күгең — күк!
Җирең — җир!

Яуларда, хезмәттә, сәнгатьтә
исемең акладык, Татарстан.
Син безне күтәрдең, без — сине —
язың — яз!
Җирең — җир!
Даның — дан!
Язың — яз!
Җирең — җир!
Даның — дан!

## *Ак пионнар*

Бакчаларда инде ак пионнар
шатлык тулы чәчәк аттылар.
Яныбызга ник килмидер, диеп,
алар карый миңа аптырап.

Төннәрендә Айдан — көмеш нурлар,
томаннардан чыклар алганнар.
«Өзеләбез сөю хакына!..» — дип,
мине көтеп, тынып калганнар.

Нигә өзим, нигә өзим әле,
нигә тиим бакча ямена? —
Сагынудан өзелергә җитеп,
тиздән үзе килер яныма.

## Әйтмә миңа

Әйтмә миңа —
җәйләр узды, димә,
хисләр тузды, димә,
сүнде, димә, күмере.

Әйтмә миңа —
янып көттем, димә,
синсез үтте, димә,
гомерем.

Барысын, җаным, беләм,
ләкин яз кабат килә
саф күңелләргә.

Күрәсеңме, тагын яз,
күрәсеңме, киек каз
кайтты күлләргә.

Аны кума син,
дулкын тынмасын
күңелләрдә.

## *Җылы буран*

Җылы буран,
Җылы буран
Бер көчәя, бер тына шул,
Бер көчәя, бер тына.
Әллә ул күңелдә шулай,
Әллә шулай чынында.
Мин сине көтеп торам —
Җылы буран арасыннан
Пәйда булырсың сыман.

Җылы буран,
Җылы буран —
Гөл чәчәк койган кебек шул,
Гөл чәчәк койган кебек.
Керфегеңә сарган карны
Эретермен мин үбеп.
Мин сине көтеп торам —
Җылы буран арасыннан
Пәйда булырсың сыман.

Җылы буран,
Җылы буран...
Көтәсеңме тынганын шул,
Көтәсеңме тынганын?
Инде үзем буран булдым —
Бик ихтимал соңлавың.
Мин сине көтеп торам —
Җылы буран арасыннан
Пәйда булырсың сыман.

## *Киттең инде*

Киттең инде,
күзләремнән күптән киттең инде.
Кычкырып әйткән сүзләремнән
киттең инде.
Йөрәгемне эчтән бикле, тыштан бикле,
мәңге бикле бер буш зиндан иттең инде.
Кем коткарыр,
синнән көчле кем табылыр,
кем соң ватар йөрәгемнең йозакларын?
Үтә көннәр йозакларга тутык өстәп...
Озакладың,
коткаручым,
озакладың...

## *Муенса*

Көмеш чишмә буена
кызлар төшкән уенга.
Һәрберсендә муенса,
төрле-төрле муенса.
Муенса кигән кызның
сөйгән яры уенда.

Муенса, муенса,
өзелсә дә коелса,
коелса да таралса,
таралса да каралса,
нишләрсез икән, кызлар?
Нишләрсез икән, кызлар?
Муенса, муенса,
өзелсә дә коелса,
коелса да таралса,
таралса да каралса,
беләсезме, нишләрбез,
беләсезме, нишләрбез?

Курыкмабыз, җайларбыз,
берәр егет сайларбыз,
икәүләшеп җыярбыз,
чишмәләрдә юарбыз,
ефәк җепкә тезәрбез,
түшебезне бизәрбез.

Икәүләшеп җыярбыз,
чишмәләрдә юарбыз,
бергәләшеп санарбыз,
энәгә җеп сапларбыз,
ефәк җепкә тезәрбез —
сезнең хакка түзәрбез.

Тырышкан-түзгән өчен,
ефәккә тезгән өчен,
суда юышкан өчен,
ихлас булышкан өчен
ниндирәк бүләк көтә,
ниндирәк бүләк көтә?

Тырышкан-түзгән өчен,
ефәккә тезгән өчен,
сезне зур бүләк көтә:
өегезгә кайткач ук,
зур эш кыргансыз, диеп,
әниегез пәп итәр.

Муенса, муенса,
барысы да муенда.
Өзелмәде, төшмәде,
аны беркем чишмәде,
муенсалы кызларның
шуклык икән уенда...

## *Бер син генә*

Бер син генә түгел лә ул
миңа болай караган —
керфекләрен тарак итеп,
күз нурларым тараган.

Бер син генә түгел лә ул
миңа болай омтылган —
сагышлы чагымны күреп,
күзләренә моң тулган.

Бер син генә түгел лә ул
миңа болай сүз дәшкән —
акыллы киңәшләр биреп,
бәхет юлы эзләшкән.

Бер син генә түгел лә ул
миңа болай җырлаган,
кушылып бер сүз җырлашсам,
куанычтан елаган.

Ләкин Җирдә бер син генә
мине болай тилмерткән —
йөрәгемә сөю салып,
мәхәббәттә тилерткән!

## *Көмеш нур*

Идел өстенә көмеш нур
сузылган тулган айдан;
көмеш дулкыннар кузгатып
җил чыкты әллә кайдан.

Көмеш нурларга дулкыннар
кагыла җайлап кына,
йөрәгем аша үтәли
узганың сайлап кына.

Күңелгә тулган көмеш чың
бер көчәя, бер тына...
Утырам Идел ярында
гомер агышын тыңлап...

Көмеш дулкыннар өстендә
нур йөзә эзсез генә...
Моңланып җырлап җибәрәм
тын гына, сүзсез генә...

Аңлыйм да кебек җырымны,
аңламыймын да кебек...
Идел суы — кара дулкын,
ә яры — көмеш күбек...

## *Кукчәчәк*

Зәңгәр-зәңгәр кич иде...
Зәңгәр-зәңгәр кар иде...
Зәңгәрлеккә уранып,
әйтер сүзем бар иде.

Зәңгәр кичне төн алды...
Зәңгәр төнне көн алды...
Зәңгәр карлар эчендә
әйтәсе сүзем калды.

Зәңгәр язлар җитәчәк,
зәңгәр карлар китәчәк.
Сүзем калган урында
үсеп чыгар кукчәчәк.

## *Гашыйк бул син миңа*

Гашыйк бул син миңа,
Гашыйк бул син,
Вакытлыча гына булса да,
Күзләремә сеңгән
Сүнмәс яшьлек төсем
Кояш, яңгырлардан уңса да...

Гашыйк бул син миңа —
Йөрәгемдә
Беркем кагылмаган хисләр бар.
Күзләремдә минем,
Бәлки, син күрерсең,
Уңмый торган җете төсләр бар.

Гашыйк бул син миңа —
Читләп үтмә,
Күп үттеләр инде җил кебек.
Мин тын тордым...
Менә сине күргәч кенә
Мин талпынып куйдым,
Җилкенеп.

Гашыйк бул син миңа —
Үкенмәссең...
Вакытлыча гына...
Китәрсең...
Тик бер генә язга минем күңелемне
Чәчәк тулы бакча итәрсең...
Гашыйк бул син миңа...

## Елмай

Уяндыңмы — елмай!
Көнне башла шулай.
Елмай үз-үзеңә,
мендәрең бүзенә,
тәрәзәдән кергән,
өйне нурга төргән
һәрчак изге көнгә,
сәлам биргән гөлгә
елмай!

Уяндыңмы — елмай!
Көнне башла шулай.
Елмай сәбәпсез дә —
якты, әйбәт сүзләр
табарсың һәркемгә:
бәхетлегә, кимгә,
олыга, кечегә,
җиде ят кешегә
елмай!

Уяндыңмы — елмай!
Көнне башла шулай.
Зилзиләләр тынар,
чыксаң — юлың уңар,
авырлыклар арыр,
башлаган эш барыр.
Бар дөньямны бизә —
карап минем күзгә
елмай!

## Камаздашлар

Без җыелдык Камага,
Чаллы дигән калага.
Алып килде безне монда
Хыял яктырткан юллар,
Тотындык зур төзелешкә
Яшьләрчә, җиңел кулдан.

Рус, татар, башкорт дуслар,
Украиннар, чувашлар —
Менә дигән юлдашлар,
Хәзер без камаздашлар.

Без эшлибез Камада,
Чаллы дигән калада.
Яшьлегебез мәйдан тота
Халык, заман каршында.
Ватаныбыз нәрсә кушса,
Без үтәрбез барсын да.

Рус, татар, башкорт дуслар,
Украиннар, чувашлар —
Менә дигән юлдашлар,
Хәзер без камаздашлар.

Без калабыз Камада,
Чаллы дигән калада.
Үзебез салган йортларда
Яшьнәп яшисе килә.
Соклансыннар безгә карап:
Нинди тату гаилә!

Рус, татар, башкорт дуслар,
Украиннар, чувашлар —
Менә дигән юлдашлар,
Хәзер без камаздашлар.

## *Дуслык Чаллыда*

Исәнме, дисәм мин,
Аптырап калма син.
Эш юктан эндәшмим —
Күңелне аңла син.
Син минем көткәнем —
Ягымлы икәнсең.
Чаллыга килеп син
Бик дөрес иткәнсең.

Чаллыда, Чаллыда
Гаҗәеп төзелеш —
Дуслыкның куәте
Артадыр йөз өлеш!

Исәнме, дисәм мин,
Җавапсыз калма син,
Күземә кара да
Йөрәкне аңла син.
Син ерак каладан,
Мин ерак каладан,
Дуслашыйк әле без
Идел һәм Камадай.

Чаллыда, Чаллыда
Гаҗәеп төзелеш —
Дуслыкның куәте
Артадыр йөз өлеш!

## Сугыш турында сөйләшә картлар

Сугыш турында
Сөйләшә картлар.
Кырда, урамда
Гаҗәеп тынлык.
Комачауламыйк
Карт солдатларга —
Аларның сүзен
Тын гына тыңлыйк.

Аларның сүзе,
Ут-ядрә булып
Өтсә дә кайчак
Безнең бәгырьне,
Билгесез солдат
Кабере өстендә
Дөрләгән ялкын
Кебек кадерле.

Пышылдап кына
Сөйләгән сүздә
Сугыш дәһшәте
Һаман да тынмый.
Кычкырып рәхмәт
Әйтергә кыймый,
Карт солдатларны
Тирә-юнь тыңлый...

## *Ил улы — Ямашев*

Ямашев йөрәге күкрәктә,
Ямашев өмете йөрәктә.
Ул йөрәк туктамас һәм тынмас,
Ул өмет сүрелмәс һәм сынмас.
Хөсәен Ямашка
Без килдек алмашка.
Балкыйбыз, яшьнибез,
Көрәшеп яшибез.
Без — коммунистлар!
Без — комсомоллар!

Ямашев — ил улы, батыр ир,
Ямашев — каһарман, баһадир.
Ул салган сукмаклар адашмас,
Ул куйган маяклар саташмас.
Хөсәен Ямашка
Без килдек алмашка.
Балкыйбыз, яшьнибез,
Көрәшеп яшибез.
Без — коммунистлар!
Без — комсомоллар!

Ямашев — безгә дә ул яшьтәш,
Ямашев — бүген дә көрәштәш.
Ул безнең үткәннең аклыгы,
Ул безнең намусның пакьлеге.
Хөсәен Ямашка
Без килдек алмашка.
Балкыйбыз, яшьнибез,
Көрәшеп яшибез.
Без — коммунистлар!
Без — комсомоллар!

## Сөекле Казан

Ак та син, пакь тә син, Казан.
Өметтәй якты син, Казан.
Йөрәктә мәңгегә саклансын
Шул якты чаткысы, Казан.
Иделдә, Иделдә
Дулкыннар уйный,
Күзләрем, күзләрем
Сокланып туймый,
Күңелем, күңелем
Гел сине уйлый,
Батырлар шәһәре —
Сөекле Казан!

Энҗе кар япкач та, Казан,
Чәчәккә баткач та, Казан,
Син матур төнлә дә, көндез дә,
Сызып таң аткач та, Казан.
Иделдә, Иделдә
Дулкыннар уйный,
Күзләрем, күзләрем
Сокланып туймый,
Күңелем, күңелем
Гел сине уйлый,
Эшчәннәр шәһәре —
Сөекле Казан!

Сүзең дә үтәрлек, Казан,
Даның да җитәрлек, Казан.
Син диеп җырладык, син диеп
Бер биеп җибәрик, Казан.
Иделдә, Иделдә
Дулкыннар уйный,
Күзләрем, күзләрем
Сокланып туймый,
Күңелем, күңелем
Гел сине уйлый,
Гашыйклар шәһәре —
Сөекле Казан!

## *Яшь Магелланнар*

Җирнең шар кебек булуын
Магеллан исбат иткән.
Җир түгәрәк кенә түгел,
Ул бик гүзәл дә икән.
Юлга, юлга,
Яшь Магелланнар!
Һәр урында,
Һәрбер эштә
Сокландыргыч хәлләр бар.

Без барасы озын юллар
Үзәннәр, үрләр аша.
Алар, һичшиксез, кайдадыр
Зур серләргә тоташа.
Юлга, юлга,
Яшь Магелланнар!
Һәр урында,
Һәрбер эштә
Шаккаткыч ачышлар бар.

Каравелла, киер җилкән,
Дулкыннар ярдыр әле!
Абагалар чәчәк аткан
Аланнар бардыр әле!
Юлга, юлга,
Яшь Магелланнар!
Һәр урында,
Һәрбер эштә,
Һичшиксез, Магеллан бар.

## *Нурлы Казан*

Нурлы Казан! Синең якты нурың
Рухым өчен минем дәвалы,
Ул нур бәхет өчен
Изге көрәшләрдә
Кабынган ялкыннар дәвамы.

Дәртле Казан! Тизлек заманасы
Сиңа салган иркен юл аша
Минем хәләл көчем
Илем куәтенә
Синең мәйданыңда тоташа.

Моңлы Казан! Көчле җырларыңа
Кушыла бит минем тавыш та.
Мин бәхетле бала,
Син бәхетле кала,
Җырыңда юк кайгы-сагышлар.

Казан, Казан! Минем назлы калам,
Син мәңгегә күңел түрендә.
Минем барыр юлым,
Синең киләчәгең
Якты язмыш булып күренә.

## *Мәңгелек Казан*

Син, Казаным, чордан чорга
имин атлап керәсең.
Һәр улыңа, һәр кызыңа һәрвакыт
якты өмет бирәсең.

Мин яратам сине, Казан, яратам!
Синдә үсә бәхет гөлем.
    Әй, Казаным, язмышыбыз бакчасы,
    бәхет телим,
    бәхет телим!

Син, Казаным, чорлар аша
мәңгелеккә барасың.
Һәр улыңа, һәр кызыңа көч бирә
синең кыю карашың.

Мин яратам сине, Казан, яратам!
Синдә үсә бәхет гөлем.
    Әй, Казаным, язмышыбыз бакчасы,
    бәхет телим,
    бәхет телим!

## *Мин сине яратам, ахры*

Мин сине яратам, ахры, —
һәрвакыт сине уйлыйм.
Уйларым татлыдан-татлы,
шуңадыр уйлап туймыйм.

Мин сине яратам, ахры, —
көне-төне сагынам.
Сагынуым тәнем буйлап
җылы нурдай агыла.

Мин сине яратам, ахры, —
җырга кушам исемең.
Син исеме булдың инде
Минем сөю хисемнең.

## *Коммунистлар*

Без — коммунистлар. Вакыт ашкына,
маягы итеп безнең максатны.
Очышы иркен, очышы мәгърур —
Ленин байрагы — чорның канаты.

Без — коммунистлар — хезмәт кырында
кешелек Җирен бизәп чигүче;
яу кырларында фидакарь батыр,
хәтта сугышның үзен җиңүче!

Без — коммунистлар — чыныккан халык
яңа дәверне тудырган утта
Туган илгә дә һәм кешегә дә
безнең мәхәббәт бер кайнарлыкта.

Без — коммунистлар! Безнең юл дөрес,
моңа инаныр җирдә бар кеше —
чөнки чор үзе сәгате итте
коммунистларның йөрәк тибешен!

## Алтын аланда

Җәйдән дә җылырак көне
була икән ич көзнең!
Шундый көн алтын аланга
китерде безне.

Урманның якты сагышы
нур булып күзгә керә.
Мәңге җанда калыр әле
шушы хатирә.

Җылы якка киткән кошлар
болытларга сала эз.
Шул кошларга иярмәкче
көмеш пәрәвез.

Бөтерелә һаваларда
әллә кош, әллә яфрак,
хушлашулар моңы тора
һаваларда яңрап.

Ә безнең китәсебез юк,
безгә биредә рәхәт —
моңаерга ирек бирми
көзге мәхәббәт.

Язгы ташкындай шашкын ул,
җәйге төн кебек серле.
Нәкъ беренче мәхәббәттәй
йөрәктә дөрли.

## *Таллар башы кызара*

Кар астына су төшә,
бозлар калка инештә.
Күңел ачык кочак кебек —
күңелгә яз килешә.

Таллар башы кызара,
дулкынлангыч көннәр килә
егетләргә, кызларга.

Кошлар тора кагынып,
берсен-берсе сагынып,
янгын көткән йөрәкләргә
ялкын китә кабынып.

Язның галәмәтләре —
көннең, төннең һәр мизгеле —
кавышу сәгатьләре.

Парлар тора тын гына,
иреннәре дым гына.
Егеткә кыюлык җитми,
кызга исә — моң гына.

Җил бозларны кубара...
Зәңгәр бозларга ияреп
ялгыз чак китеп бара.

## *Шушы шатлык*

*(Табын җыры)*

Шушы шатлык, бәлки, кабатланыр,
көзге җилләр искән чагында...
Язгы җилләр дуслык анты булсын
һәр табында
икмәк алдында!

Шушы җырлар, бәлки, кабатланыр
кышын, җәен, тагын, тагын да...
Җыр китергән ләззәт уртак булсын
һәр табында
икмәк алдында!

Шушы бәхет, бәлки, кабатланыр
заманалар кичкән агымда...
Уртак бәхет җырга әверелсен
һәр табында
икмәк алдында!

## *Мәңгелек яз*

Кар, яңгыр, томан
ташкыннарын кичтем,
сагыш күленең суларын эчтем.
Ләкин сусадым —
сусадым назга...
Менә очрадым
мин мәңгелек язга.
Мәңгелек язның
татыдым назын.

Аһ, нинди матур
миләүшәле таңнар!
Минем таңнарга,
бәхеткә хакым бар.

Син — минем таңым,
мәңгелек язым,
сүнмәс бәхетем,
сүрелмәс назым.

## *Белем маршы*

Шатланып ачып керәмен
мәктәп ишеген —
белемнең зур көч икәнен
белгән кеше мин.
Яңгыра, көмеш кыңгырау,
безне каршыла —
кушыл әйдә һәм куәт бир
«Белем маршы»на!

Шатланып ачып керәмен
мәктәп ишеген.
Бар көчемне биреп уку —
минем төп эшем.
Яңгыра, көмеш кыңгырау,
безне каршыла —
кушыл әйдә һәм куәт бир
«Белем маршы»на!

Шатланып ачып керәм мин
мәктәп ишеген.
Ишетәмен Ватанымның
йөрәк тибешен.
Яңгыра, көмеш кыңгырау,
безне каршыла —
кушыл әйдә һәм куәт бир
«Белем маршы»на!

## *Әй җанаш!*

Казан каласына өч көнлек юл,
Әй җанаш, моңайма.
Атлар яхшы, барып җитәрбез.
Әй җанаш, моңайма.
Атлар яхшы, барып җитәрбез.

Казан каласында өч тирән күл,
Әй җанаш, моңайма.
Өчесен дә йөзеп үтәрбез.
Әй җанаш, моңайма.

Казан каласында өч йөз мең йорт,
Әй җанаш, моңайма.
Шуның берсен җәннәт итәрбез.
Әй җанаш, моңайма.
Шуның берсен җәннәт итәрбез!
Әй җанаш!
Әй җанаш!

## Тәрҗемә турында

Мин тәрҗемәче түгел. Ләкин минем татар телендә ишетәсем килгән, башка телләрдә иҗат ителгән шигырьләрем күп. Аларны хәтта яраткан, зәвыгымны тәрбияләшкән шигырьләрем дип тә әйтергә була. Ул шигырьләр күңелем сандыгында балачактан бирле саклана. Бик күптән А.С.Пушкинның «Делибаш» шигыре мине үзенең манзаралыгы, гадилеге һәм тапкырлыгы белән шаккатырган иде. Төрек сүзе делибашның һич көчәнүсез татарча тилебаш булып яңгырарга тиешлегенә ышанып, мин бу шигырьне тиз генә, телдән генә, тәрҗемә итеп тә куйдым һәм, озак еллар кәгазьгә төшермичә, үземнең «авыз иҗаты» буларак сакладым. Тәрҗемә дөньясына минем беренче җитди адымым әнә шулай булды.

Прозаны, драматургияне тәрҗемә итү ни дәрәҗәдә иҗаттыр, мин анысын белеп бетермим, әмма шигырьне тәрҗемә итү — авыр, ләкин ләззәтле иҗат. Авторның җаны никадәрле катлаулы булмасын, аны аңлау — мөмкин эш. Әмма башка телле шагыйрьнең тел стихиясен үз теленнең шигъри калыбына югалтуларсыз сыйдыру — бик сирәк очракларда гына була торган хәл. Шигырь шагыйрьдә иректе агым белән туа. Шагыйрь үзенең әсәрен күңеле күгеннән инде формалашкан, барлык сүзләре дә диярлек үз урынын тапкан әсәр итеп тартып ала. Ягъни, оригиналь шигырьдә иректе очыштагы сүзләр шагыйрь тылсымы белән бөтен бер мәгънәле җөмләләргә әверелгән булалар. Ә тәрҗемәдә — киресенчә: авторның җөмлә-мәгънә кысаларында гаҗәеп матур яңгыраш тапкан сүзләренә тиң-тәңгәл булган үз телең сүзләрен табарга кирәк. Кайбер иң мөһим очракларда, әйтик, рус сүзләренең татарчалары, татар сүзләренең русчалары булмаганда, нишләмәк кирәк? Шуның өстәвенә шигырьдә янәшә килгән сүзләр өстәмә мәгънә белән байыйлар. Ә тәрҗемә иткәндә ул сүзләр йә янәшә була алмыйлар, ә булган очракта үзләренең тылсымнарын югалталар. Шагыйрь — үз шигыренең хуҗасы, ә тәрҗемәче — шигырьнең колы булырга мәҗбүр. Ә кол хезмәтен күз алдына китерергә мөмкин, һәм бу коллык сине баета торган, акылыңны ялкаулыктан арындыра торган бер халәт...

Тәрҗемәне берничә принципка таянып эшләргә була. Әйтик, тәрҗемә, оригиналның эчтәлегенә тугрылыклы калган хәлдә, аның формасын да, рифмалау ысулын да, ритмикасын да, яңгыраш стилен дә, метафора һәм сурәтләү чаралары үзенчәлеген

дә мөмкин булганча тулы сакларга тиеш. Моңа ирешеп булса, әлбәттә, мондый тәрҗемә идеаль тәрҗемә булыр иде. Дөресен әйтим, татарчадан русчага, бигрәк тә русчадан татарчага тәрҗемә шигырьләр арасында мин андыйны бер генә тапкыр да очрата алмадым. Мондый төгәллеккә татарчадан башкортчага, башкортчадан татарчага тәрҗемә иткәндә генә ирешеп була торгандыр.

Мин үзем бераз үзгәрәк принцип тарафдары: татарча «җырлап» торган шигырь, төп метафорасын саклаган хәлдә, башка телләрдә дә «җырлап» торсын. Тәрҗемәдә оригиналның башка хасиятләре күпме мулрак сакланып калса, шуның хәтле яхшырак, әлбәттә. Мине иң беренче нәүбәттә шигырь метафорасының тирәнлеге, күпкатлылыгы, шагыйрьнең образлар системасы җәлеп итә. Һәм мин фәкать шундый шигырьләрне генә тәрҗемә итәм.

# РУСЧАДАН

## Гаврила ДЕРЖАВИН

### Хөкемдар һәм судьяларга

Калыккан да тиңсез Аллаһ, хөкем итә
Дөньялыкның бихисап күп аллаларын;
Кайчангача, дип әйтә ул, кайчангача
Сез аярсыз яманнарны, усалларны?

Бурычыгыз сезнең: кануннарны саклау,
Көчлеләрнең кемлегенә карамыйча,
Ятимнәрне һәм толларны беркайчан да
Ярдәмсез һәм яклаусыз һич калдырмыйча.

Бурычыгыз сезнең: бәлаләрдән йолу
Гаепсезне, бәхетсезгә терәк булу;
Көчлеләрдән көчсезләрне аралау һәм
Мескеннәрне богаулардан азат кылу.

Ишетмиләр! күрә торып төшенмиләр!
Бәбәкләрен ришвәт, бүләк томалаган,
Явызлыклар җирнең тәнен тетрәтәләр,
Ә күкләрнең эчен айкый-чайкый ялган.

Патшалар! Сез Аллаһ кодрәтенә ия,
Сезгә һичкем судья түгел сездән элек.
Әмма сез дә нәкъ минем кебек языклы,
Әмма сез дә гүр иясе — минем кебек.

Сулган агач яфраклары өзелгәндәй
Өзелерсез әле сез дә вакыт җиткәч,
Иң әшәке колыгыз үлеп киткәндәй,
Үзегез дә бер үләрсез ахыр чиктә.

Калкын, Аллаһ! Калкын, хаклылар Алласы!
Ишетә күр ялваруларын шуларның:
Хөкем ит һәм җәзала мәкерлеләрне,
Һәм бердәнбер патшасы бул Җир шарының!

*1780 (?)*

## *Кошчыкка*

Бер сайрар кошны тоттылар,
Учларына кыстылар.
Чәрелди кошчык, ә аны
«Сайра!» диеп кыстыйлар.

*1792 яки 1793*

## *Шук теләк*

Әгәр сөйкемле кызлар
Очсалар мисле кошлар,
һәм кунсалар ботакка, —
мин ботак булыр идем,
меңләгән кыз-кыркынны
шунда кундырыр идем.
Утырып җырласыннар,
җайлы оя корсыннар,
балалар чыгарсыннар;
мин һич бөгелмәс идем, —
һәм булыр идем шулчак
мин иң бәхетле ботак.

*1802*

* * *

(«Река времен в своем стремленье
Уносит все дела людей...»)

Вакыт дәрьясы үзенең агымында
алып китә инсан эшләренең барын
һәм батыра онытылу чоңгылында
патшалар, патшалыклар һәм халыкларны.

Әгәр дә ки ни дә булса кала калса
трубалар һәм лиралар тавышы аша,
аларны да мәңгелекнең зур авызы
чәйнәп йотар һәм дә булмас язмыш башка.

*6 июль, 1816*

## Тончига *

Үлемсез Тончи! Ишетәмен, син ният
Кылгансың сурәтләргә минем затымны,
Борынгы Гомер йә батыр Аристидны,
Гакыллы Сократны йә кырыс Катонны
Сурәтләгән олы осталыгың белән
Килер буыннарны шаккатырмакчысың;
Чал чәч һәм пеләш балкышы аркылы
Кеше үзе күренеп торырлык булсын.

Пеләш булу, әллә париклар йөртүме,
Әллә тога, әллә кыска, тар мундирмы
Сине бөеккә эверелдерүчеләр?
Һич юк! Фәлсәфәң һәм Музаларың җыры;
Шулар безне шулай данлыклы кылалар.
А! Әгәр дә хаклык рухы торса тиеп
Һәм яктырта калса мине дан нурлары,
бик килешер иде миңа һәрбер кием.

Шулай, фәлсәфәче рәссам! Сурәтемне
Төрле сәер киемнәрдә ясап ал бер,
Белгәнеңчә: ләкин гакыл ияләре
Мәхәббәтлелеген дә беркетеп калдыр.
Бөекләргә әгәр кайбер йомшаклыклар
Хас булсалар, син шуларны да эндәшми-
Нитми миндә чагылдырырга онытма,
Аларга да елмайсын әле көнләшү.

---

* Т о н ч и — Г.Р.Державинның портретын ясаган Италия рәссамы.

Юк, син мине тупас табигыйлегемдә
Бик һәйбәтләп кенә сурәтләргә тиеш:
Зәмһәрирдә җанына ялкын-ут капкан,
Йонлач бүрек һәм җылы тун кигән килеш;
Табигатьнең әмеренә ияртелеп,
Җил-давыллар җиңеп, тауга менә барыйм,
Һәм күренсен бозлы якта туганлыгым,
Ерак бабам булганлыгы морза Бәгърем.

Хатынымны, дус-ишләремне куркытма,
Мине бераз мөлаем итсәң дә ярый:
Балаларны назга төрим, тик вазифам
үтәгәндә, мин кырыс карар чыгарыйм.
Каным минем дөрләгән уттан кайнасын,
Күз нурларым йомшак булсын, сынмасыннар;
Платоник сөюдән генә булса да,
Чибәркәйләр миңа карап уфтансыннар.

## *Давыл*

Каегым диңгездә кайный —
Кара дулкыннар эчендә;
Ян-якта чал таулар шаулый...
Таянам өмет көченә.

Кем ул болытлар ялкынын
Сүндерүче баш очыннан?
Кем кулы ул каегымны
Яшерде таш ышыгына?

Син, Дөньяны яратучы!
Бөртек чәчем дә башымнан
Синсез төшми. Син коткардың
бу һәлакәт ялгышыннан!

Гомеремне озайттың син,
Рухым синең алда ачык;
Түрәләр рәтенә керттең,
Калканым бул һәм юлбашчым.

# Аллаһ

Йа Син — ирек-иркенлектә иксез-чиксез,
матдәдәге хәрәкәттә җанлы-тере,
вакыт агышында мәңгебакый булган
өч чырайлы, өчесе дә йөзсез Тәңре!
Һәркайда бар һәм бердәнбер рух-сәгадәт,
Сиңа кирәк түгел урын, һичбер сәбәп.
Асылыңа синең беркем төшеналмас,
Бар нәрсәне үзең белән тутыргансың,
Урагансың, нигезләгәнсең, коргансың,
Һәм исемең телебездән төшми, — АЛЛАҺ!

Океаннар тирәнлеген үлчи алган,
Барлый алган комнар санын, нурлар көчен
Олуг акыл табылса да бу дөньяда,
Сан табылмас, Аллаһ, Сине үлчәр өчен.
Яктылыгың нурларыннан Синең туган,
Синең рухың белән мәгърифәтле булган
Беркем Синең язганыңны үзгәрталмас.
Уй-хыяллар гына, ашып Синең катка,
Бөеклегең тирәнлекләренә бата
Мәңгелектә мизгел эрегәндәй, АЛЛАҺ!

Вакыттан да элгәре булган хаосны
Мәңгелекнең төпкеленнән Син чакырттың.
Барыннан да алдан туган мәңгелекне
Син үзеңдә нигезләдең һәм бар иттең;
Үзең белән син үзеңне төзеп кордың,
Үз нурыңнан үзең нурдай балкып тордың,
Яктылыкка чишмә булып иң-иң элек.
Тик сүз белән бар нәрсәне яралдырдың,
Һәр яңада Син үзеңне иҗат кылдың,
Син бар идең, Син бар бүген, Син мәңгелек!

Сыйдыргансың Син тереклекнең чылбырын,
Асрап тәрбия итәсең өздермичә,
Башлау белән төгәлләүне ялгыйсың Син,
Яшәүгә үлем бирәсең сиздермичә.
Чәчри очкын, берсен берсе куа-куа,
Һәм кояшлар, шулай чәчрәп, Синнән туа;

Аяз, суык кышкы көндә бозланган кар,
Бәс тузаны ялтыр-йолтыр иткән сыман,
Чиксез күкнең чиксез тирән карасында
Җемелдәшә Синнән аста йолдызлыклар.

Мильонлаган якты җисем күкләр буйлап
Үлчәмсезлек агымында агып бара.
Алар Синең кануннарың хаклылыгын
Терек нурда коендыра һәм сугара.
Ләкин якты утлы шушы лампадалар,
Яки алсу кристаллардан хасил таулар,
Яки алтын дулкын чөйгән кайнар күбек,
Яки ургып-дөрләп янган төнге эфир,
Яки якты нурга чумган бар галәм, Җир
Синең янда — көн каршында тик төн кебек.

Диңгезләргә тамган тамчы чаклы гына
Шушы каты катлам Синең алларыңда;
Һәм нәрсә ул мин күзәтә торган галәм?
Һәм мин үзем нәрсә инде Син барында?
Һава океаннарын мин яуласам да,
Дөньяларны мильонга тапкырласам да
Җөрьәт итмәм — чагыштырып карый алмам —
Чагыштыру мөмкин түгел Синең белән;
Бөтен нәрсә нокта гына, үзем белән,
Мин дә бер юк нәрсә генә Синең алда.

Бер юк нәрсә! — Әмма миндә Син балкыйсың,
Игелегең бөеклеге агылгандай.
Миндә үзең үзеңне үк сурәтлисең,
Бер тамчыда бөтен кояш чагылгандай.
Бер юк нәрсә! — Әмма мин тормышны тоям,
Һич туймыймын, һәм дә, канат какмый, кыям
бер татырга күк гөмбәзенең тарлыгын.
Минем җаным-тәнем Сине шундый сөя,
Ул уйлана, ул төпченә, фикер чөя:
Мин — бар! Димәк, шиксез Синең дә барлыгың!

Син бар! — диләр табигатьтәге тәртипләр,
Йөрәгемнең һәр тибеше аңлата гел,
Раслый моны минем төпченгән акылым:
Син бар — һәм мин инде бер юк нәрсә түгел!

Мин бу бөтен бер галәмнең бер өлеше,
Һәм уйлыймын, Синең сайлау миңа төште —
Иң мөхтәрәм чик-ызанга мине куйдың:
Монда бетә, тәгәлләнә җанварларың,
Һәм башлана шушында ук рух-җаннарың,
Һәм Син миннән бу чылбырга ялгау койдың.

Һәр төштә бар дөньяларга ялганыш мин,
Мин матдәнең иң җитлеккән, биек очы;
Тормыш итү мәгънәсенең үзәге мин,
Илаһилык сыйфатлары башлангычы;
Тәнем чери, көлгә әверелә, бетә,
Ә акылым яшенгә идарә итә —
Мин патшамын — мин кол, мин корт — мин Аллаһмын!
Әмма ләкин булсам да шундый могҗиза,
Ничек бар булдым?— дип уйлап чигәм иза;
Үзлегемнән булалмадым һәм алмамын.

Синең иҗат җимешең мин, Бар итүчем,
Синең акыл, Синең кодрәт йөзек кашы,
И Яшәүләр чыганагы, Игелеклем,
Җаным җаны һәм дә аның Падишасы!
Синең хакны хаклар өчен кирәк булган
Чиксез үлем төпсезлеген кичә алган
Минем үлемсез яшәеш-үзлегем дә;
Рухым фанилык киеме кисен өчен,
Үлем аша кичеп янә килсен өчен,
Атакаем, Синең үлемсезлегеңә.

Аңлату да төшенү дә мөмкин түгел!
Мин беләмен җаным ничек теләгәнне —
Әмма ул да күз алдына китералмас
Һәм сурәтли алмас хәтта күләгәңне;
Ләкин Сине данларга кирәк чакларда
Һәм моңа без фаниларның хакы барда,
Моны эшләр өчен әмәл һич юк түгел:
Безгә кала Синең катка юл аласы,
Аермабыз арасында югаласы
Һәм рәхмәтле күз яшьләре кою-түгү.

# А.С.Пушкин

## Тилебаш

Ике лагерь күз алдында
Үрләрдә атыш бара.
Кызыл киемле тилебаш
Казакның күзен яра.

Тилебаш! Кызган җаныңны,
Алай хәтәр очынма,
Шаяруың эләктерер
Сине сөңге очына.

Һәй казак! Син дә ашкынма
яу кырына, бул сабыр —
кылычы белән тилебаш
башыңны чабып алыр.

Берсе берсенә ыргылды.
Күрегез, шундый эшне —
Тилебаш сөңгедә. Казак...
башы тәгәрәп төште...

* * *

(«Я вас любил: любовь еще, быть может,
в душе моей угасла не совсем...»)

Сөйдем сезне: бәлки, гыйшкым һаман
Сүнеп бетмәгәндер җанымда;
Тик ул сезне башка борчымасын;
Моңлатасым килми тагын да.
Сөйдем сезне сүзсез һәм өметсез,
Куркаклыктан талып, көнләүдән;
Сөйдем сезне шулай — Ходай язсын
Сөелергә башка берәүдән.

## *Баратынскийга*

*Бессарабиядән*

(Сия пустынная страна
Священна для души поэта...)

Ошбу тыныч, иркен һәм буш яклар
Шагыйрь җаны өчен изге ул:
Державинның җырларында алар,
Һәм рус даны белән туп-тулы.
Бүгенгәчә Назонның шәүләсе
Дунай ярын эзли биредә;
Һәм ул оча, Аполлонның татлы
дәшү авазына бирелеп.
Шәүлә белән мин дә бик еш йөрим
Текә ярда, моны Ай күрә;
Тик үзеңне җанлы Овидийны
кочкан кебек кочу ямьлерәк.

*1822*

# М.Ю.ЛЕРМОНТОВ

## Берьялгызым юлга чыгамын мин

**1**

Берьялгызым юлга чыгамын мин;
Чакматаш юл балкый томан аша;
Төн тын. Бушлык тыңлый тәңре өнен,
Йолдызлар белән йолдыз аңлаша.

**2**

Күк гөмбәзе тантаналы, гүзәл!
Җир йоклый күгелҗем балкышында...
Ник соң авыр? Әрним һәм чак түзәм?
Нидер көтәм... кызганаммы шунда?

**3**

Көтмим инде тормыштан һичнәрсә,
Үткәндә юк берни кызганасым;
Җанга ирек, тынгы эзлим!.. Килә
Онытылып йокыга таласым!

**4**

Ләкин кабер йокысына түгел...
Шундый мәңгелек йокы телимен —
Яшәү көче, тынып, черем итсен,
Сулу алсын күкрәгем тилпенеп;

**5**

Төннәр, көннәр буе татлы тавыш
Сөю турында җыр сузса икән,
Яшеллеккә мәңге керә-керә,
Шауласын иелеп куе имән.

* * *

(«Я жить хочу!.»)

Мин яшәргә телим! сагыш телим
Сөю-сәгадәткә үч атып;
Акылымны шулар узындырды,
Маңгаемны артык шомартып.
Вакыт, вакыт тынгылык томанын
Кудыртырга зәһәр көлүдән,
Газапларсыз шагыйрь яшимени,
Давылларсыз океан кем күргән?
Газап, зарыгулар исәбенә
Ул яшәргә тели... Аңлы юл...
Ул тавышлар сатып ала күктән,
Дан-шөһрәтне бушлай алмый ул.

* * *

(«Послушай, быть может, когда мы покинем...»)

Тыңла әле, без мәңгегә китсәк бергә
җаныбызга суык өргән шушы җирдән,
алдашулар юк бер илдә, бәлки, бик тиз
булырбыздыр син фәрештә, ә мин иблис.
Әй сөеклем, син вәгъдә бир — шундый чакта
җәннәт назын онытырга минем хакка.
Язмыш сөргән кеше сиңа җәннәт булсын,
сине миңа иксез-чиксез галәм кылсын!

# Федор ТЮТЧЕВ

* * *

(«Нам не дано предугадать...»)

Сүзебезнең ни булып кире кайтасын
Бирелмәгән безгә алдан белеп тору —
Бәрәкәт ничек бирелгән булса безгә,
Мәрхәмәт бирелүе дә шулайдыр ул.

* * *

(«Умом Россию не понять...»)

Акыл белән Россияне булмый аңлап,
Үлчәп булмый күнегелгән аршын салып:
Ул үзенә бер бөтенләй башка калып,
Россиягә була бары тик ышанып.

* * *

(«И дым отечества нам сладок и приятен!..»)

«Төтене дә ватанның безгә һуш һәм татлы!» —
Диеп әйткән үткән гасыр шагыйрәнә.
Безнекендә — эзли талант кояшта тапны,
Сасы төтен белән Ватанын ыслый әнә.

* * *

*К.Б.*

(«Я встретил вас — и все былое...»)

Очраттым да сезне — бар үткәннәр
Туңган йөрәгемдә терелде;
Алтын чорлар искә килеп төште —
Һәм җылыга йөрәк төренде...

Шундый көннәр була һәм сәгатьләр —
Җирдә инде көзнең салкыны,
Яз аңкышы кинәт чыга да, һәм
Нидер куя бездә талпынып, —

Җаным тулы теге елларның мин
Җилләренә биреп үземне,
Күптән онытылган ләззәт татып,
Ала алмыйм сездән күземне,

Әйтерсең лә безне аеры торткан
Гасыр аша, сихри төш аша
Карыйм сезгә — җаным теге чакта
Сез кабызган хискә тоташа...

Хатирәләр генәмени соң бу,
Тормыш үзе җырлый кабаттан, —
Шул ук балкыш сезне нурландыра,
Шул ук сөю мине яңарта!..

* * *

(«Когда дряхлеющие силы...»)

Хыянәт итә башлагач
Какшый барган көчләребез,
Без яңа килмешәкләргә
Урын бирергә тиешбез, —

Шул чакларда коткара күр,
Мәрхәмәтле даһи, кызып,
Әләкләүдән, сүгүләрдән
Үзгәргән тормышыбызны;

Яшерен үчләшүләрдән
Яңарып барган дөньяга,
Анда яңа кунакларга
Табын корган, шәраб ага;

Агымда булмауны сизеп,
Селтеләнеп ачынудан,
Анда башка омтылышлар
Һәм бүтәннәр бара алда;

Һәм башка шундый нәрсәдән,
Чөнки күптән мәгълүм соңы, —
Карт гыйшкыннан хурлыклырак
Бәйләнчек картлык ярсуы.

* * *

(«Все отнял у меня казнящий бог...»)

Бар нәрсәмне алды җәзалаучы Аллаһ:
Саулык, йокы, ихтыярымны алдырды,
Үзен зурлап гыйбадәт кылдыртыр өчен
Яннарымда бер сине генә калдырды.

## *Декабрь иртәсе*

Ай әлегә күктә — төннең
Күләгәсе хәрәкәтсез,
Хөкем сөрә, уйламый да
Талпынуын көннең эзе.

Ялкау гына, кыймый гына
Нур арты нур туа анда...
Ә күк әлегә тулаем
Балкый төнге тантанада.

Ике-өч мизгел дә узмас,
Җир өстеннән төн таралыр,
Һәм көндезге дөнья безне,
Кинәт балкып, биләп алыр...

* * *

(«Над этой темною толпой...»)

Уянмаган бу халыкның
Бу томана өеренә
Кайчан килерсең, Азатлык,
Алтын нурларга төренеп?..

Сирпелер нурың, терелтер,
Йокың томанын җилгәрер...
Тик карт, черегән яралар,
Золым һәм үпкә җөйләре,

Җан аздыру һәм йөрәктә,
Һәм анда бушлык изасы, —
Кем соң шуларны дәвалар?..
Син, Гайсаның пакь ризасы...

# Владимир МАЯКОВСКИЙ

## Ә сез булдыра алырсызмы?

Мин бердән бутадым көннең карталарын,
стаканнан буяу сибеп җибәрдем дә;
океанның чыгынкы битендә яңагын
күрсәттем мин бер табак дерелдәвектә.
Тәңкәсеннән калай балыкның укыдым
яңа ироннәр дәшүен, сабырым сынып.
Ә сез
яңгыр торбалары флейтасында
берәр ноктюрн
уйнап бирә алырсызмы?

## Мыскыллаулар

Фантазиямне тавис коерыгыдай кабартам да,
җанны атам күтелмәгән рифма өере иркенә.
Тегеләрнең —
үзләрен туендырган имән тамырын
танау белән актаручыларның —
гәзит баганаларында ыржайганнарын
яңадан ишетәсе килә.

## Айлы төн

*(Пейзаж)*

Ай булачак.
Инде
беленә.
Менә эленде дә тулы укасы.
Аллаһ, ихтимал,
гаҗәеп
көмеш кашык белән
болгатадыр йолдыз ухасын.

## *Тыңлагызчы!*

Тыңлагызчы!
Әгәр дә йолдызларны кабызалар икән —
димәк — бу кемгә булса да кирәк?
Димәк — кемдер аларның булуларын тели?
Димәк — кемдер шул төкерекчекләрне
энҗе бөртекләре дип атый.
Һәм, челлә тузаннары давылында
хәлдән таеп,
Аллаһ янына бәреп керә,
соңгардым дип, куркып,
елый-үкерә,
аның сеңерләнеп калган кулларын үбә,
һәрвакыт бер генә булса да йолдыз булсын дип
үтенә! —
йолдызсызлык газапларын
күтәрә алмаячагына ант эчә!
Ә соңыннан,
тыштан тыныч күренсә дә,
сыза эчтән.
Кемгәдер сүз ката:
«Хәзер сиңа ярыйсы ич?
Куркыныч түгел һич?
Әйеме?»
Тыңлагызчы!
Әгәр дә йолдызларны кабызалар икән —
димәк — бу кемгә дә булса кирәк?
Димәк — бу мөһим эш —
һәр кич
өй кыеклары өстендә
бер генә булса да йолдыз кабыну?!

## *Яз*

Шәһәр кышкысын салды.
Селәгәен тыймый кар кере.
Тагын да яз. Хәтерләтә салкын,
аңгыра, сафсатачы юнкерны.

# Сергей ЕСЕНИН

* * *

(«Над окошком месяц...»)

Тәрәздә тулган Ай. Тәрәзне җил какты.
Яфраксыз тополькай көмештәй яп-якты.

Бер тальян, ялгызы сыкранаерактан —
Җанымдай кадерле һәм ерак йөрәктән...

Елый да көлә дә, бәгырьгә дә үтә.
Кайда соң син, юкәм? Йөзьяшәр төз юкә?

Үзем дә кайчандыр бәйрәмдә таң-иртән
тальянда уйнадым, ишетсен дип иркәм.

Ә хәзер аңарга берни дә түгелмен,
ят җырга кушылып, көләм, яшь түгәмен.

* * *

(«Цветы мне говорят — прощай...»)

Гөлләр миңа «Хуш! Хуш!» диләр,
башкайларын тәмам иеп,
аның йөзен, туган ягың
мәңге күралмассың диеп.

Әй, сөеклем, бәлки, бәлки!
Ә мин күрдем — бәлкем, аздыр...
Бу җан чыгу тетрәнүен
кабул итәм яңа наз дип.

Гомер сөрү асылына
җиткәнгә күрә елмаеп,
«бөтен нәрсә кабатлана!»
дип әйтәмен мизгел саен.

Барыбер ич — килер бүтән,
сагыш күммәс киткән ярны,
яхшырак җыр бүләк итәр
кадерләмә яңа пары.

Сөеклем, җыр тыңлый-тыңлый,
яңа яр белән янәшә,
кабатланмас бер җыр итеп,
искә алыр мине дә, шәт.

* * *

(«Выткался на озере алый свет зари...»)

Күл суларына чигелде таңның ал төсе.
Имәнлектәге суерлар җибәрде үксеп.

Кайдадыр шәүләгән елый, куышта ятып,
Мин генә менә еламыйм — күңелем якты.

Беләм ич, кичен чыгарсың юллар аркылы,
Утырырбыз чүмәләгә, кибән артына.

Исерткәнче үбәрмен мин, гөлдәй изәрмен,
Кем гаепләр куанычтан сәрхуш исәрне?..

Назга чыдамый салырсың фатаң ефәген,
Таңгача куак төбенә алып китәрмен.

Имәнлектә елый бирсен шунда суерлар,
Таң-шәфәкъ алсулыгында хозур сагыш бар.

## Анна АХМАТОВА

* * *

(«И слава лебедью плыла...»)

Аккош булып йөзде даным,
төтен аша сөзелеп.
Ә син, сөю, һәрчак булдың
минем өметсезлегем.

### Исем

(«Татарское, дремучее
Пришло из никуда...»)

Татарныкы, каракуе,
Килде беркая яктан,
Һәр бәлагә ябышучан,
Үзе дә — бәла хәтта.

### Ике юллы шигырь

(«От других мне хвала...»)

Башкаларның мактаулары — көл генә бары,
Синең яманлавың хәтта — мактаудан ары...

# *Марина ЦВЕТАЕВА*

* * *

(«Два солнца стынут...»)

Ике кояш сүнә — йа Ходаем, кичер, кызган! —
Берсе — күктә, икенчесе — күкрәгемдә, сызлап.

Шул кояшлар — кичерәмме, әллә аз булырмы? —
Шул кояшлар мине акылымнан яздыруны!

Суыналар алар — авырттырмый нурлар агып!
Беренче булып сүнәр аларның кайнаррагы.

*6 октябрь, 1915*

* * *

(«Как правая и левая рука...»)

Әйтерсең лә уң кул белән сул кул,
Синең җаның минем җанга якын.

Кушырылганбыз, җылы һәм рәхәт,
Әйтерсең уң канат һәм сул канат.

Өермә калка — һәм упкын ача
Уңыннан канатның сулынача!

*19 июль, 1918*

# *Игорь СЕВЕРЯНИН*

## *Хөкүмәткә поэза*

Бөек шагыйрьләрен иплəп зурламаса,
үзен дә ул үзе хөрмәт итми ласа,
танылуга илткән юлга вето баса,
йөзенә келәймә суга хөкүмәт.

Рәссамнарын пушка янына бастырса,
иңнәренә авыр мылтыклар астырса,
үз баласын палач кулына тапшырса,
жандармны хәтерләтә хөкүмәт.

Мохтаҗлыкка тәмам баткан язучыга
субсидия салмыйча сузган учына,
әдәплеләр алар диеп, бик тә чыдам,
дошманлык кына арттыра хөкүмәт.

Цензура белән янаса хәкименә,
хурлык корымына буялып кимендә,
шигырь белән бу эшкә булышам мин дә,
таратылырга лаеклы хөкүмәт.

Даһиларын җәберләүгә күнә-күнә
тыныч кына карап торса дүнә-дүнә,
әнә шундый вандаллар хөкүмәтенә
хаклы рәвештә лаектыр җәмгыять.

# Николай ЗАБОЛОЦКИЙ

## Ялкауландырма җаныңны

Ялкауландырма җаныңны!
Су төймәсен дисәң киле,
Җан хезмәт итәргә тиеш
Көне-төне, төне-көне!

Каула аны йорттан йортка,
Этаптан этапка сөйрә,
Такырга, чытырманлыкка,
Кар көртенә керә-керә.

Таң йолдызы яктысында,
Аунатма аны түшәктә,
Тот иренчәкне кубектә
Тезгененнән урап шәпләп!

Беразга эштән бушатып,
Үзсендермәк булсаң аны,
Синең соңгы күлмәгеңне
Кызганмыйча йолкып алыр.

Иңнәренә аның ябыш,
Интектер — күрсен күрәсен,
Кабат кешечә яшәргә
Ул синең белән өйрәнсен.

Ул колыңмы, ул патшаңмы,
Ул оланың, хезмәтчеңме,
Ул хезмәт итәргә тиеш
Көне-төне, төне-көне!

# Арсений ТАРКОВСКИЙ

* * *

Төнлә вакыт акрын бара узып.
Кәбисә ел бетә-төкәнә.
Карт нарат тамырлары янә
Тоялар сумалалары бозын.

Миңа көнлек мәшәкатьләр җиткән,
Башка бәхет миңа кирәкми.
Беләм: анда койма терәтеп,
Кемдер елы җиткән ахыр чиккә.

Беләм: яңа урман калкып бара,
Безнең наратларга тоташып.
Тамырлары белән укмашып,
Үз нәүбәтләрен алар тоялар.

## *Василий ФЕДОРОВ*

### *Сэнгать*

Без матурлыкның мәгънәсе
Турында бәхәсләштек.
Ул сабыйларча самими
итеп миңа эндәште:
— Мин сул сәнгать тарафдары,
син фикер әйтеп кара...
— Сул яклы... ләкин йөрәктән
булмаганда сулдарак.

## Станислав КУНЯЕВ

* * *

(«Молчим, работаем, поем...»)

Дәшмибез, эшлибез, җырлыйбыз,
Яшибез сагышлы мәзәктә,
Сугар да сәгате — һәм килер
Бер давыл һәм салыр газапка:
Сугышмы, башка бер афәтме
Җандагы гамьсезлек тынчуын
Болгатыр, актарыр, чайпалтыр —
Күрсәтер намусның чын суын.
Һәм шулчак без мәҗбүр булырбыз,
Шар ачып җаныбыз капкачын,
Расларга: без — чынлап гүзәллек
Һәм кырыс хакыйкать яклаучы.

# *Михаил ЛЬВОВ*

## *Сезнең күзләр*

Туганнарым, азиатлар,
Аңлый алмыйм мин һаман:
Учаклар төтәгәнгәме
Күзегез кысык калган,
Йә яшен-укларыгызга
Чыдамасын дип калкан
Җәя тартканга мәңгегә
Күзегез кысык калган...

# *Вадим КУЗНЕЦОВ*

## *Сал*

Акрын,
акрын,
акрынрак тын ал —
Чиремештә* черем итә бер сал.

Кара төндә ап-ак бер төш
күрәдер, мөгаен:
имештер, ул — яңадан урман:
нарат, имән, каен.

Имештер, ул язга чыккан,
тора яфрак ярып...
Имештер, ул гомумән белми
Җирдә балта барын.

Имештер, сут уйнап ага
яфракка тамырдан...
Туган җирдә төшләр тәмле.
Тик... тиздән агарга...

Акрын,
акрын,
зинһар, акрын,
акрынрак тын ал...

* Чиремеш — Себердәге бер елга.

## *Смоленск диварлары янында*

Бу диварлар итәгенә
күмелгәннәр арасында
бер генә рядовой да юк —
полковниклар барысы да!

Таш өстендәге гөлләрдән
искән җилләр нидер эзли...
Әй, кадерле полковниклар,
гаскәрегез кайда сезнең?

Кайсы курганнар астында
ята алар тавыш-тынсыз,
танышырга да өлгерми
һәлак булган дусларыгыз —

яшьләр, картлар, урта яшьләр,
кара чәчле, сары чәчле...
Барысын сугыш җир буйлап
исемсез үр итеп чәчте.

Кабер ташыгыз өстенә
бер яфрак шәүләсе ятты...
Ял итегез, полковниклар,
намусыгыз тапсыз, якты!

Солдатларыгыз белән сез
кергәндә суга ялкынга
уйламадыгыз дәрәҗә,
данлы бүләкләр хакында!

Шөһрәт кушкан өчен генә,
йә булмаса җиңел кулдан
сипмәдегез, полковниклар,
солдат башын уңга-сулга!

Җавап тотулардан куркып,
качмадыгыз таш кабергә —
сезнең язмыш ахыргача
солдатныкы белән бергә!..

Мәңгелек утның ялкыны
җылыта таш диварларны...
Шәүләсе ташларга төшә...
Батырларны ялкын барлый!

* * *

*Николай Старшиновка*

Каенның яшел чәченнән
чал-сарысын өз!
Борчылма!
Бар да тәртиптә —
бусагада көз.

Җырлагандай яшәдек, көн
тезгенен тотмый.
Әйләнеп баксак,
күкләрдә
торналар сыктый.

Карасак,
авыл артында
кибәннәр үскән.
Карасак, алмагачларда
алмалар пешкән.

Күрми дә калганбыз,
дустым,
көннәр узганны.
Күктә, торналар янында
вакыт тузаны.

Үткәргәнбез гомер җәен
шаяру катыш.
Көзләр безне гафу итсә,
гафу итмәс кыш...

## *Валерий ШАМШУРИН*

* * *

(«Когда тебе все звёзды светят...»)

Барлык йолдыз сиңа балкыганда,
хөкем — бары илһам һәм сәләт.
Күреп алулары сине — әйбәт,
әмма хәтәр — күккә чөйсәләр.

Юк, андый эш һич шаяру түгел,
бәла агуына бал кушу.
Иң гайрәтле кайнар елларыңны
тончыктырыр даның балкышы.

Кыямәт көн җиткәч уянырсың...
Чик узылган, кире юл ябык...
Һәм үзеңнән үзең көләрсең син,
елый алмаганга, көч табып.

Шул вакытта сине юатырлык
беркем, берни булмас катыңда:
туган йортың, бакчаң кәлиткәсе,
ап-ак чәчле сөйгән хатын да...

* * *

(«Быть может, вовсе ни к чему...»)

Бәлки, һич тә кирәкмидер
җен көлдереп, дан алырга, —
дип кычкырам алгарышның
дуамал хуҗаларына.

Җаннары ишетсен диеп!..
Яктылык һәм караңгылык,
кое төбендәге кебек,
кушылды куркыныч булып.

Эшләр барып җитте шуңа:
акыллыгың бәласын,
бәхәссез зарурият дип,
йөрәк түреңә аласың...

* * *

(«Наступило время никакое...»)

Әллә нинди вакыт килде әле...
Арынып булмый кара сагыштан,
әйтерсең без — туган җирдә качак,
үзебезгә үзебез яу-дошман.

Кем әле без?
Нинди эшләр өчен?
Нинди шатлык, бәхет хакына?
«Птица-тройка»* ягалайлап үтте,
кыңгыраулар тынды артында.

Һич югында әрем бассын иде —
чүп-чар күмә көннәр, кырларны.
Көтү-көтү козгын оча, көтеп
безнең чәйнәшүләр корбанын.

---

* Птица-тройка — (Н.Гоголь) Русь, Россиягә ишарә.

* * *

(«Знакомые звуки доходят до слуха...»)

Таныш моңнар колакка җитәләр,
иске җырлар кебек иркәләп.
Агачларның яшел кыңгыравы
дала өсләп шаңдый-тирбәнә.

Ни турында хәбәр сала бу шау,
борчу, сагышларны таратып?
Яфрак гөмбәзләрне җилләр чайкый,
агачларның җырын яңартып.

Имәнлекләр шавын тыңлау рәхәт,
күрү шатлык чалгың чабышын...
Артка карыйм — күрмим гомер башын,
алда күрмим бетәр чагын мин.

* * *

(«Стараюсь не для медали...»)

Тырышуым медаль өчен түгел,
язам сөеп, уйдан бүзәреп,
шигырь укысыннар диеп түгел,
укысыннар диеп үзләрен.

*Эдуард БАЛАШОВ*

## *Ничаклы*

Бернәрсә дә аңламыйча,
Үз-үзеңне кочаклыйсың.
Ничаклы яратсаң аны,
Аңлыйсың да шул чаклы син...

# *Наталья АСТАФЬЕВА*

* * *

(«Мой росточек, мой листочек...»)

Үрентечек,
Яфракчыгым,
Җып-җылы бөрем...
Бәлки, кыздыр,
Бәлки, улдыр —
Белми дә йөрим.
Минем җаным,
Тамчы каным,
Таң йолдызчыгым,
Әле яшерен
Куанычым,
күм-күк бозчыгым.
Туфракка бөртек төшкәнгә
Беренче атна.
Тәнемдә бәләкәй кояш
Җылытып калка.

# КАЗАХЧАДАН

## Олжас СӨЛӘЙМАНОВ

### Куып тот!

Куып җит мине, егет,
атың күбек ит, егет,
әгәр мине чынлап сөйсәң,
куып тотарсың кебек.
Сине яратам, егет,
куып җит тә
ал үбеп.
Оялудан тавышым
тамагыма ябышты.
Мине җил куып уза,
ул билемә кул суза.
Аһ, егет артка калды,
атымы әллә талды.
Үчекли мине Ай-кыз,
мин ялгыз,
Айдай ялгыз.
Кулларым инде талды,
атымның сырты канлы.
Эх, сез усал кешеләр,
сез бит миннән көлгәнсез:
шундый батыр егеткә,
шундый матур егеткә
туры чаптар урнына
хәлсез ишәк биргәнсез!..

* * *

Поездлар соңгаралар.
Яшел семафор — харап.
Мәтәлде сары йолдыз —
самолетлар соңгара.

Мәрхәмәтле гасырның
хәкиме каш җыера —
күзеннән аккан нурны
керфек тоткарлап тора.
Барыбер лә: ни ялвар,
ни ачу белән эндәш —
чыбыркы озынлыкка
соңгара синең киңәш.
Киләчәкнең шәүләсе
портретның түсен казый,
сөеклем, ничә елга
соңгара синең назың!
Клавишлар буйлата,
Листка ярдәм дип уйлап,
дастаннан ирләр кайта,
соңгарып
өч йөз елга...

* * *

Думбырасын чиртә-чиртә,
бер карт акын
бик күптән
җырлый мәхәббәт турында,
инде карлыгып беткән.

Ялпәк йөздән, мыеклардан
хасил җанлы түгәрәк...
Юртага ишәк ышкына...
Атлар эткә тибәләр...

Кемнәрдер моңга кушыла...
Акын белә җырлавын.
Юртага
сөялгән килеш
йоклый сөңге урманы.

## *Аргамак*

Әй, сез, кыпчак далалары,
данлы ат көтүләре!
Кипкән үлән яңгырында
айгырлар утлап йөри.
Бир миңа яшь аргамакны —
уйный җан тамырларым,
шәһәрен дә, даласын да
җилим бер, җилен ярыйм.
Аргамакның кайнар канын
җил өреп ялкын итәр,
тояк
          очырган
                    очкыннан
үләннәр янып китәр.
Аргамакның аңына да
һөҗүм тәме
          иңәр бер...
Куркак
          сукмаклар
                    йөзенә
тояклар шавын бәрик!..

# УКРАИНЧАДАН

## Тарас ШЕВЧЕНКО

* * *

(«Куковала кукушечка..»)

Кәккүк күкелдәп җибәрде
Яшел имәнлектә.
Кыз бала елап җибәрде
Сөелмәгәнлектән.

Ә кызның матур еллары
Заяга үтәләр,
Дулкындагы чәчәк кебек
Агалар-китәләр.

Әти-әниләре исән,
Хәллерәк тә булса,
Табылыр иде сөюче,
әйбәт яучысы да.

Шулар юк шул. Берьялгызым
Үк-кадерсез генә
Гөл кебек сулып сынармын
Бер читән төбендә.

# *БЕЛОРУСЧАДАН*

## *Рыгор БОРОДУЛИН*

### *Хатын-кыз*

Хатын-кызны
изге үк итмәгез —
ул тормыштан,
гүя алмагач.
Давыллансын,
җанын дәваласын —
хәсрәт урып,
бала табалгач.

Төнге сагыш,
көндезге күз яше
болыннарның тыныч чыгында.
Чәнечке дә,
иң назлы бизәк тә,
йолдызлы җан да ул
чынында.

# БАЛКАРЧАДАН

## Кайсын КУЛИЕВ

* * *

Мәет белән хушлашканда кайчакларда
Мәгънәсездер сүзләр әйтү — нигә аңа
Җан җылысы сеңгән сүзләрне без үзе
исән чакта әйтеп кала алмаганда?

Бик еш кына безгә җылы сүзләр җитми,
Җаның туңып боздай каткач... Шул чагында
Тылсым көче белән сугарылган сүзләр
Җылыталар безне кизил учагыдай.

Җае җитми шытып чыкмый хәтта бөртек —
Туфракның ул алсын әүвәл җылы көчен!..
Чакма кебек йөрәккә дә җылы сүзләр
Кирәк була чатнап чаткы бирсен өчен ...

# ЛАКЧАДАН

## Әфәнди КАПИЕВ

* * *

Арылды.
Эзләрдә чал картлык,
Сөякләр яман көн сизенә...
Һәм кипкән күлләрдән чүлләргә
Торналар төркеме күченә.

* * *

Хәнҗәрдәге язу кебек
Кашкайларың карадыр.
Шул хәнҗәрдәге көн кебек
иреннәрең янадыр.

* * *

Үлеп гашыйк булганга
Һич юк безгә игелек...
Йөрәкләр аеры булгач,
Карлы тау башлары күк.

Тоташтырасы иде
Икебезнең йөрәкне
Бер мылтык көпшәсендә
Дары белән ядрәдәй.

Үлеп гашыйк булганга
Якты юк безгә көннән
Тәннән тән ерак торгач
тау һәм диңгез өсте күк.

Тоташтырасы иде
Тәннәребезне безнең,
Мисыр хәнҗәре тыгыз
Кынысына кергәндәй...

# ЧУВАШЧАДАН

## Педер ХУЗАНГАЙ

* * *

Яралганмын учларымны кысып учлап:
«Якты дөнья — минеке ул!» — дигән кебек.
Ә үлгәндә ике учым да ачылыр, —
Байлык булмас анда хәтта сыңар бөртек.

Мин ачмаган, минем белән бетмәс йола:
Каберемә биш тиенлек ыргытырсыз.
Ә аннары, и дусларым, җырлап-җырлап,
Биеп-биеп төрле якка таралырсыз.

* * *

Урманнарга кердем, менеп акбүз атка,
Сагышларым салдым куе каенлыкка.
Кайгы-хәсрәтләрне башта саклап йөртсәң,
Әйләнү ихтимал шыр тиле-ахмакка.

Чирмешән буйларын байкадым-айкадым,
Бер генә уч колмак та җыя алмадым.
Шушы чиккә җиттем, васыятем итеп
тапшырырга, дуслар, берни дә калмады.

Дөньялары чиксез, Җире йомры икән,
Гомер сәкесе дә иркенәеп беткән.
Шушы чынбарлыкның серен ачар өчен
Бер кеше гомере артык кыска икән.

# *Яков УХСАЙ*

## *Мине татарга санылар*

Мине татарга санылар,
кыстыйлар: «Чәйләп алыйк!»
Һәм түбәтәй кидерәләр,
чак кына кыңгыр салып.

Охшаган икән — охшаган!
Чуваш нигә тансын соң:
миндә татар кыяфәте —
тумыштан ук анысы!

Зур күзләр, татар күзләре,
нык тупсалы киң яңак...
Татар белән аралаштык
гасырлап кына санап.

Мәҗит Гафури белән без
Уфада күп күрештек...
Зур шагыйрь булырга шулчак
хыялланды бу кеше.

Мин, сагынып, өенә дә
килә идем кайвакыт.
Каршылый иде ул җырчы,
самоварын кайнатып.

«Шундый шагыйрь булсаң икән!» —
дип өметләндем күпкә.
Каурый төрткән канатларым
тарттылар мине күккә.

Әле бер билгесез шагыйрь,
унҗиде яшь ул чакта,
татар җырлары җырладым,
үз-үземне кочаклап...

Охшарга теләдем аңа —
гаҗәеп шагыйремә.
Шуңадыр шигырьләремдә
гафурилык күренә.

Һич тә ерак тарих түгел,
ул көннәр якын, тере —
Муса Җәлил, балкып, миңа
Мәскәү күрсәтеп йөри.

Мусаның җан яктылыгы
йөрәгемдә чагылды.
Шуңадыр да инде, бәлки,
миндә татар чалымы.

Казанда еш була идем.
Җәлилсез дә күп киләм.
Шуңадыр чуваш Ухсайны
татарлар яхшы белә.

Яшьлекне искә төшереп,
барлыйм урамнар рәтен,
ә янымда Хәсән Туфан —
минем чал ахирәтем.

Аның җаны якын миңа —
ачам бар серләремне.
Аяк асларында ташлар
йомшаклар, мендәрмени!

Туфанча язарга теләп,
үзәкләрем өзелә.
Шуңа күрә дә татарлык
саркыгандыр йөземә.

Чын күңелдән үгетлиләр:
«Түбәтәеңне салма!..»
Әйтерсең мине түбәтәй
чын татар итә ала.

Охшаган икән — охшаган!
Чуваш нигә тансын соң:
миндә татар кыяфәте
тумыштан ук анысы.

# *Порфирий АФАНАСЬЕВ*

## *Җиңү көне*

Белмим, әллә күрдем, әллә әни
сөйләгәне генә хәтердә:
керде күрше... «Сугыш бетте!» — диде...
Сискәнде өй... Тетри хәзер дә...

Яраланып ике атна элек
кайткан әти басты аякка.
Калтырады ул таянган өстәл,
култыгыннан төште таяклар.

Шулчак әти мине күреп алды.
Күтәрде дә чөйде югары —
әйтерсең лә ул баһадир егет,
авыр яралары юк аның!..

Йөгереп чыкты якты урамга ул,
баш өстенә мине күтәреп...
Шуннан бирле мин, ирекле коштай,
иңлим илнең азат күкләрен...

* * *

Юк, булмады инде... Зинһар, кичер,
Чаткы чатнамады күңелдә.
Хатларымны минем тәмам оныт —
алар башка кызга иделәр.

Һәм кочма да. Барбер җылысы юк.
Калтырата... Салкын җилмени...
Көзге агач, сары яфрак ябып,
җылыталмый инде күңелне...

## *Дуслыкның нигезендә*

Йөрәгем чатнап китте дә,
мин түзмәдем, инәлдем:
«Тизрәк килеп җитә күрче!..»
«Вакытым юк!..» — димәдең.

Миңа якты шатлык иңде.
Аңа синсез тимәдем.
«Тизрәк килеп җитә күрче!..»
«Вакытым юк!..» — димәдең.

Күңелне бүлешә алу
дуслыкның нигезендә...
...Ә мин килә алырмынмы
чакырган мизгелеңә?..

## *Су эзлибез*

Җир чокыйбыз — су эзлибез.
Көн эссе. Сынды чыдам...
Бәлки, шушы катламнан соң
чишмәсе бәреп чыгар?!

Су табылмас бу төштә —
түкерик лә бу эшкә...
Юк! Ярамый! Эзлик, эзлик!
Хурлык ич ташланган эш.

Аркаң таш булып катса да,
тагын бераз казып төш!
Алдым берне батырып —
урра! — чишмә ялтырый!

Су эзлибез — су табабыз!
Зуррак шатлык бармы соң?!
Сусаганнар! Су эчегез —
сусыныгыз басылсын!

# Юрий СЕМЕНДЕР

## Идел тавышы

Дулкыннар ярга яталар
чылбыр-чылбыр.
Тавышлары колагымда:
«Юл бир, юл бир!»

Идел, синең юлың бар ич —
ашкын, ашкын!
Салларың бар, ак пароход —
ташы, ташы!

Су түгелдер ярларыңда —
көчтер, көчтер.
Шуңа күрә дә таләбең:
«Эш бир, эш бир!..»

## Әни

Сине кояш йөрәк диләр, әни.
Кояш кебек җиргә кунасың.
Кояш нурын йөрәгеңә туплап,
иртән кабат кояш буласың.

Сине юкә чәчәгедер диләр,
баллы телең өчен, яратып.
Өй катында үскән юкә кебек
син көтәсең безне һәрвакыт.

Сине язгы шәүлегәндер диләр,
җырлавыңны кошка тиңләптер...
Күңелеңнең гүзәл чиксезлеге
галәм киңлекләрен иңләрлек.

## *Карт солдатны куму*

Дүрт сугышта ничә окоп
казыган ул, биргән көчен.
Җир аны үлемнән йолган
кыю, эшчән булган өчен.

Һәм ветеран дөнья куйды...
Җирдән тагын шул ук кадер! —
окоплар дәвамы итеп,
яшьләр казый аңа кабер.

## *Нужа*

— Сине нәрсә ат җигәргә өйрәтте?
— Нужа.
— Сине нәрсә ерак юлда сөйрәлтте?
— Нужа.

— Ялкаулыкны синдә нәрсә сындырды?
— Нужа.
— Ә кулыңа нәрсә калач тоттырды?
— Нужа.

* * *

Алло!
Россиянең ике очы
кочак булып шулчак кавышты.
Элемтәнең тылсымы ишетте
ике мәхәббәтнең тавышын.

Элемтәнең тылсым көче бирде
ерак тавышларга яңгыраш...
Алло!
Ләкин сүзләр яңрамады —
елый иде чөнки гашыйклар...

* * *

— Тынычлыгың тәрәзәдән очтымы —
иртән-кичен, әни, кая карыйсың?
Чыклы таңдай бүзарма, әни, алай,
урынында шәрык, гареп, барысы...

— Ландыш төсле чыклар, улым, чирәмдә,
кошлар китәргә җыена түгелме?
Күптән киткән әтиең дә көтәдер,
аңа минсез бик кыендыр тегендә...

— Йөрәгеңне, әни, алай кузгатма
сандыгыңнан киемен ала-ала...
Ашыкма да, юксынма да... Дәшерләр
вакыт җиткәч... Ә хәзер тамак ялга.

— Киленкәем, кабартмаң кояш төсле,
ашар иде әтиегез дә тәмләп...
Чиркәү чаңы — Җир һәм Күк ризалыгы,
бераз гына шул чаңны көтик мәллә?

— Әбекәем, уч астыннан карап, син
торналарның очышын күзлисеңме,
әллә инде йолдызлар арасыннан
мин очасы юлны да эзлисеңме?

— Әй оныгым, орлыгым-чувашчыгым,
үс, күтәрел, йолдызлар коча-коча...
Мин ерактан сиңа теләк теләрмен,
аккошлар төркемендә... оча-оча...

## *Карлыгач балладасы*

Карлыгачкай очты ерактан-ерактан,
зәңгәр Нил диңгезгә ашыккан бер яктан.

Очты җил-яңгырда, сәмумнар үткәрде,
язның ул җып-җылы сәламен күтәреп.

Исенә төшерде әнисе сайравын,
ояда аңарга урын-җир җайлавын,

мамыгы каурыйга әйләнгән чакларын,
беренче мәртәбә канатын какканын...

Һәм менә Сыр суы, һәр авыл — тал-тирәк.
Чувашстан, син кабат чибәрдән чибәррәк.

Тирә-юнь — яшел шау, эш шавы — таң аткач...
Исәнме, әй туган авылым Анаткас!

Кайта да карлыгач, ни күрә — өе юк,
баз гына ыржайган... Төшә ул коелып...

Кабергә озаткач карчыкны, кайтканнар
шәһәрдән уллары, йортларын сатканнар...

* * *

Йылтыр-йылтыр йолдыз-чылтыр,
чәчрәп төшеп, урнашты
Цивиль-су ярында яткан
авылына чувашның.

Һәм бу авыл шул вакыттан
хикмәтләргә бай булды...
Тәүгесе — ат абзарында
йолдыз-кашка тай туды...

## *Коралчы Калашниковка*

Автоматлар иясе Калашник агай,
Исемең дә, эшләрең дә синең данлы.
Лаеклы рәвештә алган мактауларның
белмисеңдер инде хәтта төгәл санын.

Кайчакларда ләкин сискәнә торгансың,
кинәт килгән утлы уйларга уранып,
ничә күзнең нурларын сүндергәндер дип,
якты аңың тудырган үлем коралы...

## *Көлтә бәйлим*

Язның сихәт үләннәреннән,
бодайны сайлап берәм-берәм,
көлтә бәйлим.

Кояшның тере нурларыннан,
йолдызның моңлы кылларыннан
көлтә бәйлим.

Кайнар мәхәббәт гөлләреннән,
нәфрәт янгыны көлләреннән
көлтә бәйлим.

Өметләремнән, уйларымнан,
моңлы шигырь-җырларымнан
көлтә бәйлим.

Халкымның олы кибәненә —
киләчәгенә дигәненә —
көлтә салам.

## Өч сорау

### 1

Телче, азат лачын сыман
оча синдә туган тел.
беләсең аның чишмәсен,
саф тотасың аны гел.
Телебезнең бар тылсымын,
серен белүче кешем,
сүз тәрләнешендә бармы
бездә СӨЮ килеше?

### 2

Пәйгамбәр, изге хаклыкны
урнаштырдың йөрәккә.
Намусны саклаган хәлдә,
шул яшәргә өйрәтә.
Мин фатиха сорыйм синнән
башым иеп, бөгеп бил...
Әйтче, булырмы берзаман
Мәхәббәттән бер Инҗил?

### 3

Президентым, гүзәллекне
син игелек санадың...
Хыял якты, җир яшәрә,
яңгырый җыр, соната.
Матурга омтылу көчле,
ул ныклы ярдәм сорый:
ә хөкүмәттә булырмы
мәхәббәт министры?

# Валерий ТУРГАЙ

## Яшәү һәм үлем

Өй төзергә җыеналар...
Урыны кирәк —
Ава имән, ава тирәк.

Өй төзергә җыеналар...
Яшәргә теләп...
Үлә имән, үлә тирәк.

## Дусларга

Файдаланыгыз сез миннән,
Дуслар, файдаланыгыз!
Йөрәгем ялкыннарыннан
Җылы алып калыгыз!

Тартынмагыз! Иренмәгез!..
Ташыгыз кайта-кайта!
Мин сүнеп салкынайганчы
Алып калыгыз файда...

Файдаланыгыз сез миннән!
Мин кирәк сезгә — беләм!
Мин яшим дә сезнең өчен,
Шатлыгым бүлә-бүлә...

Файдаланыгыз, дусларым,
тартынусыз һәм шиксез!
Сезгә кирәклегем белән
мин бәхетлемен чиксез!

* * *

— Яратып туймадыңмы әле?..
— Яратып туймадыммы?
Мин
Ярату тәмен менә эчтем.
Яңа туган сабый ич мин.

— Көрәшеп туймадыңмы әле?
— Көрәшеп туймадыммы?
Мин
Көрәшү хисен яңа эчтем.
Яңа туган сабый ич мин.

— Тормыштан ялыктың мәллә?
